ПӘНҖЕШӘМБЕ
11 АПРЕЛЬ
1940 ел
№ 84 (5884)
Аерым номеры 10 тиен

БАРЛЫК ИЛЛӘРНЕҢ ПРОЛЕТАРИЙЛАРЫ, БЕРЛӘШЕГЕЗ!

КЫЗЫЛ ТАТАРСТАН

ВКП(б) Өлкә Комитеты, Шәһәр Комитеты, ТАССР Верховный Советы һәм Шәһәр Советы органы.

РЕДАКЦИЯ АДРЕСЫ: Казан, Матбугат йорты. ТЕЛЕФОННАР: экономик һәм культура бүлекләре 18—22, авыл хуҗалыгы 4—58, партия бүлеге һәм матбугат күзәтү бүлеге 14—75, хатлар бүлеге 21—28, информация һәм совет төзелеше бүлекләре 5—86, тенге редакция 3—75, типография 36—60, бухгалтерия һәм игъланнар бүлеге 2—19.

ИНДИВИДУАЛЬ ТҮТӘЛ БАКЧАЛАРЫНА ЗУР ИГТИБАР

Партиянең XVIII нче съезды Советлар Союзының промышленность үзәкләре һәм зур шәһәрләре тирәсендә бәрәңге-яшелчә базасы төзергә кирәклек турында сугышчан директива бирде. Бу, хезмәт ияләренең материаль-көнкүреш шартларын тагын да яхшыртуга, азык продуктларының мул булуына, промышленность үзәкләрен, индустриаль шәһәрләрне яшелчә белән тулысынча тәэмин итүгә юнәлдерелгән чараларның берсе. Моны үтәү өчен эшчеләрнең һәм хезмәткәрләрнең индивидуаль түтәл бакчаларын бөтен чаралар белән үстерү гаять әһәмиятле урын тота. Җәмагат оешмаларының, предприятие җитәкчеләренең бурычлары—индивидуаль түтәл бакчаларын үстерүгә дәүләт интересларыннан чыгып бәя бирүдән һәм бу эшкә ныклы булышлык итүдән гыйбарәт.

Бу өлкәдә профсоюз оешмаларыннан зур эш таләп ителә. ВЦСПС секретариаты барлык профсоюз оешмаларын, бигрәк тә фабзавкомнарны һәм месткомнарны эшчеләргә һәм хезмәткәрләргә түтәл бакчалыгы хуҗалыгын оештыруга якыннан торып булышлык күрсәтергә мәҗбүр итте. Предприятиеләрнең профсоюз оешмалары индивидуаль түтәл бакчасы ясарга теләүчеләргә җир участкылары беркетүдә, кирәкле инвентарь һәм чәчү орлыгы табуда ярдәм итәргә тиешләр.

Яз үз көченә керде. Авыл хуҗалыгы продуктларының муллыгы өчен көрәшнең хәл иткеч көннәре килеп җитте. Бу мактаулы һәм почетлы эш өчен җаваплылык һәр кайда, һәр урында нык сизелергә тиеш. Индивидуаль түтәл бакчалыгы хуҗалыгын чын-чынлап оештыру өчен бездә чикләнмәгән мөмкинлекләр бар. Республикабызның промышленность үзәкләре һәм шәһәрләре тирәсендә җир участкылары җитәрлек. Ләкин әлегә кадәр аларның шактый өлешеннән тиешенчә файдаланылмады. 1940 нчы елның язында шәһәр тирәсендәге яраклы җирнең һәр гектарына яшелчә утыртылырга, һәр гектар, һәр участкы югары уңыш бирергә тиеш. Яшелчәдән югары уңыш алу, иң беренче чиратта, оештыру һәм җитәкчелек эшенең ни дәрәҗәдә булуына бәйләнгән.

Индивидуаль түтәл бакчачылыгының файдалы икәнлеген эшчеләр һәм хезмәткәрләр үз практикаларында күреп белделәр. Мисаль өчен Ленин исемендәге күн заводын алырга мөмкин. Биредә күп кенә эшчеләр һәм хезмәткәрләр түтәл бакчачылыгы белән шөгыльләнеп киләләр. Смернов, Фәйзуллин, Комлев, Сергин һәм башка иптәшләр үткән елны үзләренең бакчаларыннан йөзәр—йөз илләшәр пот төрле яшелчә җыйнап алдылар.

Күн заводы җитәкчеләре, партия һәм профсоюз оешмалары эшчеләрнең һәм хезмәткәрләрнең индивидуаль түтәл бакчачылыгын үстерү эшенә [illegible] кирәкле чараларны күрәләр. Цехларда беседалар, консультацияләр үткәрелә. Үзләре бакчачылык белән [illegible] иптәш Сергин (Көллә цехы эшчесе) аеруча активлык күрсәтә. Завкомның тапшыруы буенча ул беседалар үткәрә. Түтәл бакчачылыгы белән кызыксынучылар заводта күп. Завком аларның төгәл исәбен алды һәм җир участкылары беркетүдә якыннан торып булыша, кирәкле инвентарь һәм чәчүлек орлыгы табуда ярдәм итә.

Ләкин кайбер профсоюз оешмалары бу тармакта үз бурычларын үтәүдән ерак торалар әле. Моның ачык мисален җитен комбинатында күреп була. Фабком председателе иптәш Шабалина индивидуаль түтәл бакчачылыгын үстерү турында ВЦСПС секретариаты карарын үтәү өчен үзендә җаваплылык сизеп җиткерми. Түтәл бакчасы ясарга теләүчеләргә участкылар беркетү мәсьәләсе практик рәвештә хәл ителгәне юк. Иптәш Шабалина „Киров район советы башкарма комитеты комлы җир бирә, анда нинди яшелчә үссен инде" дип сукранудан уза алмый. 5 нче тегү фабрикасының профсоюз оешмасына карата да шул ук сүзне әйтергә мөмкин. Фабком председателе иптәш Муштакова бу турыда ВЦСПС секретариатының махсус карары булуын, эшчеләргә түтәл бакчачылыгы оештыруда фабзавкомнарның һәм месткомнарның конкрет булышлык күрсәтергә тиешле булуларын әлегә кадәр ишетмәгән имеш.

Кайбер предприятиеләрдә чәчүлек орлыгының үзеннән-үзе килеп җитүен көтеп яталар. Мондый караш эшкә файда китерми, әлбәттә. Кирәкле орлык материалларын урыннарда табу өчен бөтен мөмкинлекләр бар.

Мәсьәләнең тагын бер ягына зур игтибар бирергә кирәк. Быел күп меңләгән эшчеләрнең һәм хезмәткәрләрнең участкыларын эшләү өчен көрәкләр, тяпкалар, лейкалар һәм башка шундый инвентарьлар кирәк булачак. Ләкин сәүдә оешмалары акырын кузгалалар әле. Шуның белән бергә, киң куллану товарлары җитештерүче цехлары булган предприятиеләр мондый инвентарьларны үзләрендә җитештерү чараларын күрергә тиешләр.

Эшнең башка өлкәләрендәге кебек үк, бу тармакта да сыйфат мәсьәләсенә җидди игтибар бирергә кирәк. Орлыкны җиргә сибү генә җитми. Югары уңыш алу өчен яшелчә утыртуның төгәл срокларда башкарылуы, участкыларның югары сыйфатлы итеп эшләнгән булулары, иң яхшы орлык чәчелүе шарт. Үзләренең тәҗрибәләре аз булган иптәшләр булышлыкка аеруча мохтаҗлар. Шуңа күрә дә, клубларда һәм кызыл почмакларда системалы рәвештә агротехника буенча консультацияләр үткәрергә, бакчачылыктан югары уңыш алу өчен аңлату эшләре алып барырга кирәк.

Партия һәм Совет хөкүмәте хезмәт ияләренең материаль-көнкүреш шартларын тагын да яхшыртуга, шул исәптән азык продуктларының мул булуы өчен бөтен чараларны күрәләр. Эшчеләрнең индивидуаль түтәл бакчаларын үстерү [illegible] кайгырту—әнә шул әһәмиятле чараларның берсе.

СОҢГЫ СӘГАТЬТӘ

ГЕРМАНИЯ АРМИЯСЕНЕҢ ВЕРХОВНЫЙ КОМАНДОВАНИЕСЕ БЕЛДЕРҮЕ

БЕРЛИН, 10 апрель. (ТАСС). Трансоцеан агентлыгының хәбәр итүенә караганда, кичә төнгә таба Германия армиясенең верховный командованиесе түбәндәге белдерүне игълан иткән: „Бүген кичкә таба Норвегиянең [illegible] әһәмияткә ия булган барлык базалары Германия гаскәрләре кулында булды. Аерым алганда, Нарвик, Стронгейм, Берген, Ставангер, Кристиансанд һәм Осло Германиянең кулына күчте. Норвегия гаскәрләренең [illegible] каршылыгы, мәсәлән, Осло, Кристиансунд якынында бу каршылык бастырылды. Бер өлеше инде Норвегиянең авиация базаларыннан торып хәрәкәт итүче Германия авиациясе [illegible] Англия—Франция эскадрасын зур югалтуларга дучар итте. Хәзергә алынган хәбәрләргә караганда, дошманның ике линкоры һәм 2 авыр крейсеры бик нык зарарланганнар. Норвегиядә һәм Даниядә тыныч. Германиянең яңа гаскәри частьләре каршылыкка очрамыйча, Даниядән һәм Норвегиядән план буенча тиз алга баралар".

ГЕРМАНИЯНЕҢ ЮККА ЧЫГАРУЫ

БЕРЛИН, 10 апрель. (ТАСС). Германия информация бюросының хәбәр итүенә караганда, бүген иртә белән Рейтер агентлыгы Берген-Фиорд районында Германиянең кораблары [illegible] хәбәр таратты. Германия информация бюросы [illegible] белдерүендә болай диелә: „Англия авиациясе чыннан да атака ясады, ләкин бомбалар суга һәм җиргә төшеп, хәрби әһәмияте булган объектларга һәм корабльләргә зыян китермәделәр. Германиянең [illegible] алынган тулы хәбәрләр, Англия [illegible] Англия очучыларының [illegible] күрсәтәләр".

ӨЛЕРГӘН УЧАСТКЫЛАРДА КЫР ЭШЛӘРЕНӘ КИЧЕКМӘСТӘН КЕРЕШЕРГӘ

БОДАЙ ЧӘЧӘЛӘР

ЮТАЗЫ, 10 апрель. (Телефон буенча). Колхозларда язгы чәчү эшләре көннән-көн киң колач ала.

Районда 832 гектар тунга сөрелгән җир тырмаланды, 102 гектар культивацияләнде һәм 87 гектар язгы сөрү үткәрелде инде.

„Балан Туба" колхозы 9 нчы апрельдә бодай чәчүгә керешә.

К. Хәсни.

ШӨГЕР, 10 апрель. (Махсус хәбәрчебездән телеграф буенча). Соңгы вакытта кояшлы җылы көннәр туфракның өлгерүен нык тизләтте. Кыр эшләренә башлау өчен яраклы участкылар мәйданы көннән-көн арта. Байтак колхозлар язгы сөрүгә керештеләр. „Трактор" колхозы 8 гектар мәйданда язгы сөрү үткәрде. Маркс һәм Куйбышев исемендәге колхозлар аерым участкыларны сайлап сөрү эшенә керештеләр. „Шушма" колхозында язгы сөрү эшендә 14 ат эшли.

М. Хәмидуллин.

ТРАКТОРЛАР ЭШКӘ КЕРЕШТЕЛӘР

КАРГАЛЫ, 10 апрель. (Телефон буенча). Кызыл Армия районының Нәриман исемендәге колхозында тунга сөрелгән җирләрдә тырмага чыктылар. Шул ук колхозда Каргалы МТС тракторлары иртә культуралар өчен сөрү эшенә керештеләр.

Мотыйгуллин.

КОЛХОЗ КЫРЛАРЫНДА

Баулы районының „Победа", „Берлек" һәм Ленин исемендәге колхозлары сөрү эшенә керештеләр. Эшнең беренче көнендә „Победа" колхозының 4 нче бригада сабанчылары Н. Козлов, И. Иванов һәм К. Козлов иптәшләр норманы 100 процент итеп үтәделәр һәм һәр көнне эш нормасын арттырып үтәргә йөкләмә алдылар. (ТатТАСС).

Хәзерлек начар

Кызыл Армия районының „Кунар", „М. Чирмешән" һәм Карл Маркс исемендәге колхозларында эш атларының торышы гафу ителмәслек начар. Бу колхозларда атларны аерым ат караучыларга беркетмәгәннәр. „Кунар" колхозында 17 атның, „М. Чирмешән" колхозында 11 атның һәм Карл Маркс исемендәге колхозда 24 атның җилкәләрен камыт, аркаларын ыңгырчак белән бастырып бозДырганнар. Колхоз җитәкчеләре Кәлимуллин, Зайцев һәм Нуруллин иптәшләр атларга ерткычларча караучыларга шушы көнгә кадәр бер төрле дә чара күрмәгәннәр.

„Комбайн", „Беренче Май" һәм Киров исемендәге колхозларда орлыкларны чистарту төгәлләнмәгән. „Комбайн" колхозында—400 центнер, „Беренче Май" колхозында 62 центнер һәм Киров исемендәге колхозда 142 центнер солы, бодай, борчак орлыклары кондициягә китерелмәгән. Киров исемендәге колхоз орлыкларны яровойлаштыру өчен урын хәзерләмәгән.

„Беренче Май" колхозында колхозчыларның 1940 нчы елның башыннан алып эшләгән хезмәт көннәре колхозның хисап кнәгәсенә дә һәм колхозчыларның хезмәт кнәгәләренә дә язылмаган.

М. М.

РЕЙД ТӘМАМ БУЛДЫ

КАЙБЫЧ, 9 апрель. (Телефон буенча). Рейд бригадалары үзләренең тикшерү эшләрен төгәлләделәр. Тикшерү үткәрелгән 20 колхозның 5 е генә (аерым кимчелекләрне алмаганда) язгы чәчүгә хәзер икәнлеге беленде.

Районда 3.000 центнер чәчүлек орлык лабораториядә тикшерелмәгән. Авыл хуҗалыгы машиналарының һәм тракторларның ремонт сыйфаты түбән булган. Мөрәле МТС ында ремонтланган 20 трактор эшкә яраксыз дип табылды.

Районның күп кенә колхозларында атларның хезмәт көннәре атларның көрлегенә карап язылмый. Шуның нәтиҗәсендә „Көрәшче", „Искра" һәм Нәриман исемендәге колхозларда уртадан түбән һәм начар көрлектәге атларның саны 50 процентка җитә. Күп кенә колхозларда арбалар җитешми.

Районда ефремовчы звенолар формаль рәвештә генә оештырылган. Звеноларга колхоз, МТС һәм район җир бүлеге тарафыннан җитәкчелек йомшак.

Рейдкә катнашучылар кимчелекләрне ачып кына калмыйча, аларны вактында бетерү чараларын да күрделәр. Тикшерү нәтиҗәләре колхоз правлениеләренең утырышларында һәм колхозчыларның гомуми җыелышларында куелды.

Тикшерү вактында „Красное Заречье" колхозының ат караучылары белән киңәшмә үткәрелде. „Кызыл Кайбыч" колхозында авыл хуҗалыгы машиналарына ремонт ясау эшендә ачылган кимчелекләр шунда ук төзәтелде.

Рейд нәтиҗәләре 7 нче апрельдә ВКП(б) райкомы бюросында тикшерелде. Бюро утырышы рейд материалларын тикшергәннән соң, колхоз, МТС, район җир бүлеге, башлангыч партия һәм комсомол оешмаларына язгы чәчүгә хәзерлек өлкәсендә булган кимчелекләрне кичекмәстән бетерергә мәҗбүр итте. Язгы чәчүгә хәзерлектә машиналарга һәм тракторларга ремонтны сузып килүе өчен Мөрәле МТС ы директоры иптәш Уликинга навид бирелде. МТС ның политик эшләр буенча директор урынбасары иптәш Тимофиевка, МТС эшчеләре арасында политик-масса эшләрен алып баруны оештырмаса, эшеннән алынып, партия җәзасына тартылачагын кисәтеп үтте. Район җир бүлеге мөдире иптәш Суховка үзенең аппаратында кискен борылыш ясамаса, тагын да катырак чара күреләчәген әйтеп үтте.

Фирушин.

ӘЛМӘТТӘ АШЫКМЫЙЛАР

ӘЛМӘТ, 9 апрель. (Телефон буенча). Колхозларда язгы чәчүгә хәзерлекне тикшерү буенча оештырылган эшче-авыл хәбәрчеләре рейденең күпчелеге үзләренең эшләрен төгәлләделәр. Рейд бригадаларының тикшерү нәтиҗәләре районның күп кенә колхозларында язгы чәчүгә хәзерлек эшенең һич тә канәгатьләнмәслек булуын күрсәттеләр. Беренче чиратта колхозларда хезмәтне оештыру, даими звеноларга җитәкчелек итү гадәттән тыш начар тора. „Ак тау" колхозы (председателе иптәш Ризванов), „Беренче Май" колхозы (председателе иптәш Алтынбаев) һәм башка колхозларда звенолар эшкә хәзерләнмәгәннәр.

„Ирек" колхозында трактор бригадаларында эшләргә тиешле колхозчыларны да звеноларга беркеткәннәр. „Зәй" колхозының бер генә бригадасында да язгы чәчү планы юк. Бу колхозда чәчү орлыгын туплау һәм аны тазарту төгәлләнмәгән. Социалистик ярдәм тәртибендә башка колхозлардан бурычка бирелгән 234 центнер орлыкны әле дә алып кайтмаганнар. Чәчү орлыкларын агулау һәм яровойлаштыру турында бер кем дә кайгыртмый. Авыл хуҗалыгы машиналары ремонтының сыйфаты бик түбән. Ике чәчү машинасына яңадан ремонт ясарга кирәк. Арбалар бөтенләй ремонтланмаган.

„Красный Клен" һәм Ворошилов исемендәге колхозларда да язгы чәчүгә хәзерлек эше шулай начар тора.

Орлыкны тиешле кондициягә китерү эше начар. Лабораториядә беренче кат тикшерү нәтиҗәсендә орлык фондының бары 49 проценты гына кондицияле дип табылды. Икенче кат тикшерү эше бик акрын бара.

Район җир бүлеге дә, ВКП(б) райкомы да рейд бригадалары тарафыннан ачылган бу җидди кимчелекләрне бетерү чараларын күрмиләр.

З. Салахеттинов.

РЕЙД БРИГАДАСЫ КОЛХОЗДА

Эшче-авыл хәбәрчеләре рейд бригадасы Арча районының „Беренче Май № 2" колхозының (Югары Аты авылы) язгы чәчүгә хәзерлеген тикшерде. Нәтиҗәдә, бу колхозның язгы чәчүгә хәзерлеге начар дип табылды.

85 центнер вика орлыгы, силос һәм яшелчә культуралары орлыклары җитешми. 22 центнер карабодай орлыгы чәчәргә бөтенләй яраксыз. Чәчү орлыгы туплау буенча колхоз правлениесе хәзергә кадәр конкрет бернинди чара күрмәгән.

Чәчү машиналары шушы көнгә кадәр ремонтланмаган. Икенче бригаданың чәчү машинасы көздән калдырылган килеш, ындырда су астында ята. Шул ук икенче бригаданың барлык сабан һәм тырмалары, беренче бригаданың тырмалары кыш буенча кар астында яткызылган һәм аларга хәзергә кадәр кул да тидерелмәгән.

Атлар чиктән тыш ябык булуга карамастан, бүгенге көндә дә әле ялга куелмаганнар. 40 эш атыннан 7 сенең ыңгырчаклыгы һәм 2 сенең камытлыгы бозык.

Басуга тирес чыгару планы бары 50 процентка үтәлгән. Җирле ашламалардан көл һәм кош тизәге кебек ашламалар хәзерләү планнары да бары 15 проценттан 35 процентка кадәр генә үтәлгән.

Рейд бригадасы бу җитешсезлекләрне бетерү өчен колхоз правлениесе белән бергәләп тиешле чаралар билгеләде. Тикшерү вактында ачылган кимчелекләргә багышлап стена газеталарының махсус номерлары чыгарылды. Тикшерү йомгаклары актив җыелышына һәм колхозчыларның гомуми җыелышына куеп тикшерелде.

Х. Хөснеттинев.
Рейд бригадасы җитәкчесе.

ВКП(б) ҮЗӘК КОМИТЕТЫ ҺӘМ СССР СОВНАРКОМЫ КАРАРЫН ӨЙРӘНӘЛӘР

ВКП(б) ның Октябрь райкомы „Авыл хуҗалыгы продуктлары хәзерләү һәм сатып алу политикасында үзгәрешләр" турында ВКП(б) Үзәк Комитеты һәм СССР Совнаркомы карарын башлангыч оешмаларда һәм колхозчылар арасында өйрәнүне оештыру мәсьәләсе буенча район партия активы белән 9 нчы апрельдә киңәшмә үткәрде.

Бу карар турында партия райкомы секретаре иптәш Медянцев доклад ясады. Киңәшмәдән соң партия һәм комсомол оешмаларында, шулай ук колхозчылар арасында аңлату эше үткәрү өчен партия активы авылларга китте.

Биектау районының „Вперед" авыл хуҗалыгы артеле колхозчылары „Авыл хуҗалыгы продуктлары хәзерләү һәм сатып алу политикасындагы үзгәрешләр" турында ВКП(б) Үзәк Комитеты һәм СССР Совнаркомы карарын чын күңелдән яхшы дип таптылар. Карарны өйрәнү өчен колхоз правлениесенә колхозчылар, бригадирлар, колхоз правлениесе членнары, комсомолецлар һәм авыл советы депутатлары җыелды. Киңәшмәдә чыгып сөйләүче иптәш Макаров болай диде:

— Бу карар колхоз строен тагын да ныгытуга юнәлдерелгән. Ул, колхозда авыл хуҗалыгының барлык тармакларын үстерүгә, җәмагать терлекчелеген үстерүгә, дәүләт йөкләмәләрен яхшы итеп үтәүгә ярдәм итә. Бу карар—колхозлар һәм колхозчылар интереслары турында Сталинча кайгыртучанлык күрсәтүнең, колхоз строеның чәчәк атуы турында партия һәм хөкүмәт тарафыннан күрсәтелә торган кайгыртучанлыкның яңа дәлиле. (ТатТАСС).

БӘРӘҢГЕНЕ ЯРОВОЙЛАШТЫРУ

Биектау районының алдынгы колхозлары—„Тукай", „Красный Восток", „Искра" һәм Фрунзе исемендәге колхозлар бәрәңгене яровойлаштыра башладылар. Яровойлаштыручылар хәзерләү буенча 100 колхозчы 3 көнлек курсны тәмамладылар һәм эшкә керештеләр. Яровойлаштыручыларның күбесе хатын-кызлар.

Быел районда 5.600 гектар җиргә яровойлаштырылган орлык чәчеләчәк. (ТатТАСС).

Социалистик ярдәм

КОТЛЫ БӨКӘШ. (Телефон буенча). Кызыл Йолдыз районы колхозлары республикабызның чәчү орлыклары җитешмәгән Азнакай һәм Кызыл Армия районы колхозларына чәчү орлыгы белән социалистик ярдәм оештырдылар. Фрунзе исемендәге колхоз 1.011 центнер, „Ирекле" колхозы 471 центнер, „Восход" колхозы 348 центнер, „Трактор" колхозы 264 центнер, „Акчура" колхозы 227 центнер, Каганович исемендәге колхоз 231 центнер һәм башка колхозлар 105 центнер чәчү орлыгы бирделәр.

Хәзер бу орлыкларны билгеләнгән районнарына ташу эшләре бара.

Г. Кәмәсин.

Шәһәр тирәсе хуҗалыгы трестының 5 нче номерлы совхозындагы стахановчы звено (җитәкчесе иптәш Ибраһимов) 1940 нчы елда Бөтенсоюз Авыл Хуҗалыгы Күргәзмәсендә катнашу өчен кандидат итеп билгеләнде. Рәсемдә: звено эш вактында, сулда—звено җитәкчесе иптәш Ибраһимов.

А. Михайлов фотосы (ТатТАСС фотохроникасы).

Яңа Писмән районының „Вязовка" колхозында „ВКП(б) тарихының кыскача курсы"н өйрәнү түгәрәге (түбәнге звено буенча) занятиесендә.
В. Лужбин фотосы (ТатТАСС фотохроникасы).

Партия тормышы

ЭШТӘ БОРЫЛЫШ СИЗЕЛМИ

Сарман районы, „Корыч кул" колхозы янындагы башлангыч партия оешмасының отчет-сайлау җыелышында коммунистлар партиягә яңа алынганнарны тәрбияләү эшенең начар торышына, партия җыелышларының хәзерлексез үткәрелүенә, карарларның үтәлеше өчен көрәшнең һәм колхозга җитәкчелекнең йомшак булуына тукталып, оешма секретаре иптәш Сибгатуллин алдына бу җитешсезлекләрне кичекмәстән бетерү бурычын куйганнар иде. Ләкин иптәш Сибгатуллин, шушы көнгә кадәр, ул җитешсезлекләрне бетерү чарасына керешмәгән. Оешманың эш стиле искечә дәвам итә.

9 нчы февральдә булган партия җыелышында колхозда язгы чәчүгә хәзерлекнең торышы турында тикшерелә. Җыелыш колхоз председателе иптәш Гарифуллинны язгы чәчүгә хәзерлекне бөтен тармаклар буенча төгәлләргә мәҗбүр итәргә дигән карар чыгара. 8 нче мартта булган гомуми җыелышта тагын шул ук мәсьәлә тикшерелә, ләкин ул үтәлешне тикшерү тәртибендә булмый. Шуңа күрә элеккеге җыелышта кабул ителгән карар кебек үк карар кабул итә. Билгеле, эшне яхшырту өчен мондый карарларның файдасы аз була. Без аны колхозда язгы чәчүгә хәзерлек эшләренең әле дә начар торуында ачык күрәбез. Мәсәлән, колхозның производство планы төзелмәгән.

Машиналарга, инвентарьларга ремонт эше төгәлләнмәгән. Орлык чистарту һәм аны тиешле кондициягә китерү эше гафу ителмәслек начар тора.

Февральнең 19 нда булып үткән партҗыелыш тагын да характерлырак. Бу җыелыш кичке сәгать бишкә билгеләнә. Ә бу турыда коммунистларга сәгать 3 тә генә хәбәр ителә. Нәтиҗәдә җыелыш 2 сәгатькә кичегеп башлана һәм анда 5 коммунист бөтенләй килми кала. Җыелышта каралачак мәсьәлә коммунистларга җыелыш башлангач кына әйтелә. Шулай ук, ВКП(б) райкомының хәрби бүлеге мөдире иптәш Андров, „Районда массовый-оборона эшенең торышы турында", райком пленумы карарының бу оешмада ничек үтәлгәнлеген тикшерү нәтиҗәсен җыелышның көн тәртибенә кертүне тәкъдим итә. Шунсы гаҗәп: коммунистлар бу көнгә кадәр ул карарның кайчан чыгарылганлыгын да һәм аның үтәлеше кем тарафыннан тикшерелгәнен дә белмәгәннәр. Иптәш Андров әйтүе буенча ул карар 1939 нчы елның 28 нче октябрендә булып үткән пленумда кабул ителгән булган. Бу факт ВКП(б) райкомының да үз карарларын массага җиткерү турында җитәрлек шөгыльләнмәвен һәм аларның үтәлешен даими рәвештә тикшереп тормавын бик ачык күрсәтә.

Кыскасы, „Корыч кул" колхозы партоешмасы отчет-сайлау җыелышыннан үзенә тиешле нәтиҗә ясамаган әле. Яшь коммунистларны тәрбияләү һәм гомумән коммунистларның политик белемнәрен күтәрү буенча оешмада бернинди дә эш алып барылмый. Коммунистларга партия поручениеләре бирелмәү нәтиҗәсендә аерым иптәшләр (Шәйхелисламов, Зиннәтуллин) партия эшеннән читләшкәннәр. Партия оешмасында хәлнең болай торуы ВКП(б) райкомына билгесез түгел. Чөнки райком работниклары һәм аның секретарьлары да биредә еш булалар. Ләкин алар партия җыелышы үткәреп китү белән генә чикләнәләр. Кабул ителгән карарларны үтәү эшен оештыруда һәм башка мәсьәләдә партоешмага практик ярдәм күрсәтмиләр.

З. Салахеттинов.

КЕЧКЕНӘ БЕР АГИТКОЛЛЕКТИВТА

Татпромсовет системасына караган „Ширпотреб" артелендәге партоешма (парторг иптәш Апуева) политик-агитация эшләрен өзлексез рәвештә, план буенча алып баруга зур игътибар итә. Монда, 13 агитаторны берләштергән агитколлектив бар. Составы ягыннан зур булмаган бу агитколлектив сайлау кампаниясеннән соң да үзенең эшен уңышлы гына дәвам иттерә. Агитаторлардан 5 кеше артельнең цехларында, 8 кеше элекке сайлау участкысында эшлиләр.

Дөрес, январь аенда агитаторларның участкыдагы эшләре туктала дәрәҗәсенә килгән иде. Партия оешмасы бу мәсьәләне ашыгыч рәвештә тикшерде. Агитаторларның киңәшмәсен уздырды һәм элекке агитатор, яшь коммунист иптәш Фадеевны агитколлективның җитәкчесе итеп билгеләде.

Иптәш Фадеев үзенең эшен темалар сайлап алу һәм агитколлективның эш планын төзүдән башлый. Моның өчен ул ВКП(б) ның Сталин райкомына барып пропаганда һәм агитация бүлегендә эшләүче иптәшләр белән киңәшә. Райком работниклары аңа бу эштә ярдәм итәләр.

Менә агитколлективның март аендагы эш планын алып карыйк. Бу план буенча 3 нче мартта халыкара коммунистик хатын-кызлар көне турында, 9 нчы мартта иптәш Молотовка 50 яшь тулу уңае белән аның революцион эше турында, 19 нчы мартта Париж Коммунасы турында, 12 нче мартта СССР белән Финляндия арасында төзелгән солых договоры турында беседалар уздырылган. Һәрбер беседа алдыннан тыңлаучыларның сораулары буенча, газеталардан көндәлек яңалыкларны уку практикага кертелгән. Шул ук план буенча март аенда ике тапкыр агитаторларның киңәшмәсе дә уздырылган. Бу киңәшмәләрдә аерым агитаторларның отчетлары тыңланып, алдагы беседалар өчен инструктаж бирелгән һәм киләчәк айның эш планы тикшерелгән.

Иптәш Фадеев агитколлективның киңәшмәләрен уздыруга нык хәзерләнә. Агитаторларның беседаларына бара, аларның ничек эшләүләрен тикшерә. Монда агитаторларның эшенә ныклы учет алып барыла. Һәрбер агитатор, үзенең көндәлегендә, кайчан һәм нинди темага беседа уздырганны, анда ничә кеше катнашканны язып бара. Эштә ныклы учет булдыру һәм үтәлешне тикшереп тору кадрларны тапшырылган эшкә коммунистик мөнәсәбәт һәм җаваплылык рухында тәрбияли. Бу мәсьәләгә партия һәм комсомол оешмасы нык игътибар итәләр һәм агитаторларның үзләрен тәрбияләүдә иптәш Фадеевка булышалар. Мәсәлән, комсомолец-агитатор иптәш Аникин үзенә беркетелгән йортта агитация эшен алып бармаган. Бу факт иң элек агитколлектив җыелышында, аннан соң комсомол оешмасында принципиаль мәсьәлә итеп тикшерелә. Бу хәл агитаторларның эшен тагын да яхшыртуга зур йогынты ясый.

Хәзерге көндә агитаторлар СССР Верховный Советының соңгы Сессиясе материалларын, Совет хөкүмәте башлыгы иптәш Молотовның бу сессиядә ясаган докладын массаларга аңлату буенча артельнең цехларында һәм беркетелгән йортларда кызу эш алып баралар. Аннан соң, апрель ае планы буенча, Татарстан АССР ның XX еллыгына карата, дингә каршы һәм башка темаларга беседалар уздырачаклар.

З. Габитов.

МАРКСИЗМ-ЛЕНИНИЗМНЫ ӨЙРӘНҮЧЕЛӘРГӘ ЯРДӘМГӘ

Иптәш Сталинның „Милли мәсьәләне социал-демократия ничек аңлый?" дигән әсәре турында

Большевистик партиянең бөек төзүчеләре Ленин һәм Сталин ВКП(б) ның бөтен тарихы буена бергәләшеп партиянең милли-колониаль мәсьәләдәге политикасын эшләделәр. Иптәш Сталин милли мәсьәлә буенча күп кенә бик яхшы, классик әсәрләр язды, бу әсәрләр „Марксизм һәм милли-колониаль мәсьәлә" дигән исем астында бер китап итеп чыгарылдылар. Иптәш Сталин большевиклар партиясенең съездларында һәм конференцияләрендә милли мәсьәлә буенча төп докладчы булды.

Иптәш Сталин үзенең милли мәсьәләгә багышланган барлык әсәрләрендә һәм речьләрендә оппортунизмның, милләтчелекнең барлык формаларын рәхимсез рәвештә фаш итеп, Маркс—Ленин карашын өзлекле рәвештә яклап килде һәм яклый.

Иптәш Сталинның милли мәсьәлә буенча язган әсәрләренең гаять зур әһәмияте барлыкны Ленин күп тапкырлар күрсәтте. 1913 нче елны иптәш Сталинның „Марксизм һәм милли мәсьәлә" дигән мәгълүм мәкаләсе басылып чыгу белән үк, Ленин болай дип язды: „Теоретик марксистик әдәбиятта"... социал-демократиянең милли программасы нигезләре соңгы вакытларда яктыртылды инде (монда беренче урынга Сталин мәкаләсе куела). (Әсәрләр. Том XVII, бит 116).

* * *

Милли мәсьәлә буенча большевистик программаның беренче проекты 1903 нче елны партиянең II нче съездында эшләнде. Партия программасына милли мәсьәләгә кагылган түбәндәге пунктлар кертелгән иде:

„Киң күләмдә җирле самоуправление; үзләренә аерым көнкүреш шартлары һәм халкының составы ягыннан аерылып тора торган урыннар өчен өлкә самоуправлениесе".

„Сословиеләрне бетерү һәм нинди җенестән, нинди диндә, нинди расадан һәм милләттән булуына карамастан, барлык гражданнарның тулысынча тигез хокуклылыгы".

„Халыкның ана телендә белем алу хокукы, моны дәүләт һәм самоуправление органнары исәбенә кирәкле мәктәпләр төзү белән тәэмин итү; һәрбер гражданинның җыелышларда ана телендә сөйләү хокукы; барлык җирле җәмәгать һәм дәүләт учреждениеләрендә дәүләт теле белән бер тигез дәрәҗәдә ана теле кертү".

„Дәүләт составына керүче барлык милләтләр өчен үз билгеләнү хокукы".

Милли мәсьәлә буенча большевистик партиянең бу беренче проектын тагын да эшләп җиткерергә кирәк иде. 1913 нче елны иптәш Сталин үзенең „Марксизм һәм милли мәсьәлә" дигән әсәрендә болай дип язды: „...Россия социал-демократиясенең милли мәсьәләгә карашлары, әле бөтен социал-демократлар өчен үк ачык түгел.

Милли мәсьәләне җидди рәвештә һәм һәр яктан алып тикшерү кирәклеге күренеп тора" (И. Сталин. „Марксизм һәм милли-колониаль мәсьәлә", бит 9, Татгосиздат, 1939 нчы ел).

1905—1907 нче елгы беренче Россия революциясе җиңелгәннән соң, Столыпин реакциясе чорында милли мәсьәлә үзенең бөтен киңлеге белән көн тәртибенә килеп басты.

Иптәш Сталин болай дип язды:

„...Югарыдан күтәрелгән сугышчан милләтчелек дулкыны, „власть ияләре" тарафыннан ясалган бик күп репрессияләр, „ирек сөючәләре" өчен окраиналардан үч алулар,—менә болар җавап рәвешендә түбәннән милләтчелек дулкынын китереп чыгардылар, һәм бу милләтчелек вакты-вакты белән тупас шовинизмга күчә барды. Еврейләр арасында сионизмның көчәюе, Польшада шовинизмның үсә баруы, татарлар арасында панисламизм, әрмәннәр, грузиннар, украинлылар арасында милләтчелекнең көчәюе, обывательнең антисемитизмга таба гомуми тайпылышы,—болар барсы да һәр кемгә билгеле фактлар.

Милләтчелек дулкыны торган саен якынаеша барды һәм эшчеләр массасын да үз эченә алу куркынычын тудырды. Һәм азатлык хәрәкәте ничаклы кими барса, милләтчелек шул чаклы кабарынкырак булып чәчәк ата барды" (шунда ук, бит 8).

Шул ук чорда Россия меньшевиклары, бундчылар, эсерлар, милли мәсьәләдә „австрия" программасы дип аталган һәм асылда контрреволюцион булган реформистик программаны Россиядә бик тырышып җәелдерделәр. Бу программа милли мәсьәләне революцион көрәш бурычларыннан аера иде, төрле милләтләрнең пролетарийларын бер-берләреннән аера иде һәм нәтиҗәдә буржуаз милләтчелеккә китерә иде.

Билгеле, мондый шартларда большевикларга милли мәсьәлә буенча марксистик-ленинчел дөрес программа эшләргә—аны „культуралы-милли автономия" дип аталган контрреволюцион австрия программасына каршы куярга, милләтчелеккә отпор бирергә, хезмәт ияләре массасын милләтчелек агуыннан саклап калырга кирәк булды.

Менә шуңа күрә дә нәк шул чорда (1913—1914 нче елларда) „Просвещение" журналында Ленинның һәм Сталинның милли мәсьәләне һәр яклап эшләүгә багышланган күп кенә әһәмиятле теоретик әсәрләре басылып чыкты.

* * *

Милли мәсьәләнең нигезләрен һәм бу мәсьәлә буенча большевистик программаны теоретик яктан эшләп, иптәш Сталин, барлык эксплоатацияләнүчеләрнең гомуми революцион көрәше өчен милли мәсьәләнең әһәмиятен ачып бирде. Ревизионистлар милли мәсьәләне революцион көрәшнең гомуми бурычларына бәйле булмаган үзенә аерым бер мәсьәлә дип һәм шуның белән бергә саф хокук мәсьәләсе дип кенә карадылар. Иптәш Сталин милли мәсьәләнең гомуми революцион көрәшнең аерылгысыз өлеше икәнлеген, милли мәсьәләне хәл итү, изелгән милләтләрне азат итү бары тик революция юлларында гына мөмкин икәнлекне күрсәтте.

Милли мәсьәлә буенча иптәш Сталин тарафыннан һәр яктан эшләнгән большевистик программа 4 төп положениене эченә ала:

Беренче положение. Һәрбер халык өчен, һәрбер милләт өчен, ул үзенең саны ягыннан никадәр генә аз булса да, үз билгеләнү хокукы, ягъни тулысынча аерылып чыгу хокукы, үзенә аерым дәүләт булып яшәү хокукы саклана. Ләкин үз билгеләнүгә булган бу хокук, бер нәрсәгә дә карамастан, һәрбер милләт әлбәттә аерылып чыгарга тиеш, дигән сүз түгел. Мәсәлән, СССР да яшәүче аз санлы милләтләргә зур коллективта, ССР Союзында калу күп файдалырак, чөнки аз санлы милләтләрнең, аерылып чыккан хәлдә, империалистик дәүләтләрдән берсенә коллыкка төшүләре куркынычы туар иде.

Икенче положение. Шушы дәүләт чикләрендә калырга теләүче халыклар өчен большевистик программа территориаль автономия (өлкә автономиясе) принципын алга куя.

Өченче положение. Башка милләт күпчелек урын алып тора торган территориядә яшәүче азчылык милләтләргә большевистик программа иркле рәвештә милли үсешне: ана теленнән файдалану хокукын, ана телендә укытыла торган мәктәпләр төзү хокукын, үзенең милли культурасын үстерү хокукын һ. б. гарантияли. Азчылык милләтләрнең бу иркле үсеше тиешле законнар белән гарантияләнергә тиеш.

Дүртенче положение. Шушы милли хокуклар белән берлектә, большевистик программа барлык милләтләрнең эшчеләрен интернациональ туплау принципын күздә тота. Дәүләттәге бер генә милләтнең дә эшчеләре үзләренең милли кабыкларына бикләнмәскә тиешләр.

Иптәш Сталин болай дип язды:

„Урыннарда Россиядәге барлык милләтләрнең эшчеләрен **бердәм** һәм **бер бөтен** коллективларга туплау, мондый коллективларны **бердәм** партиягә туплау—бурыч әнә шул.

Үзеннән үзе аңлашыла ки, партияне болай төзү—бердәм, бер бөтен партия эчендә киң рәвештә автономияле **өлкәләр** төзүне кире какмый, бәлки аны күздә тота" (шунда ук, бит 72).

* * *

Иптәш Сталинның „Милли мәсьәләне социал-демократия ничек аңлый?" дигән мәкаләсе 1939 нчы елны „Большевик" журналының 23—24 нче номерында беренче тапкыр рус телендә басылып чыкты, бу мәкалә 1904 нче елны Закавказьедә „Пролетариат көрәше" („Пролетариатис брдзола") газетасында грузин телендә басылган иде.

Бу мәкаләнең зур әһәмияте бар, чөнки анда бөтен марксистик-ленинчел әдәбиятта беренче тапкыр буларак милли мәсьәлә буенча большевистик программа киң күләмдә аңлатылган һәм нигезләнгән. Асылда шушы мәкаләсендә инде иптәш Сталин **милли мәсьәлә буенча большевистик программаның һәм тактиканың барлык төп моментларын күтәрде һәм нигезләде.**

Иптәш Сталин бу мәкаләсендә үк инде милли мәсьәләгә сыйнфи күзлектән карады. Иптәш Сталин, милли мәсьәләнең эчтәлеге җәмгыятьнең **нинди сыйнфы** тарафыннан куелуга һәм хәл итәргә омтылуга карап төрлечә булуны күрсәтте. Мәсәлән, заманында Грузиядә дворяннарча милли мәсьәлә бар иде, аның эчтәлеге үзенә бер төрле иде; буржуаз милли мәсьәлә бар иде, аның эчтәлеге икенче төрле иде; ниһаять, пролетариатча „милли мәсьәлә" мәйданга чыкты.

Иптәш Сталин болай дип язды:

„Көрәш мәйданына яңа сыйныф—**пролетариат** килеп чыкты һәм аның белән берлектә „яңа милли мәсьәлә", **пролетариат „милли мәсьәләсе"** туды. Пролетариат дворяннардан һәм буржуазиядән никадәр аерылса, пролетариат тарафыннан куелган „Милли мәсьәлә" дә дворяннарның һәм буржуазиянең „милли мәсьәләсеннән" шул кадәр үк аерылып тора" („Большевик" № 23—24, бит 58).

Иптәш Сталин милли мәсьәләне бер кемгә дә, бер нәрсәгә дә бәйле булмаган, үзенә аерым мәсьәлә дип карамый, бәлки пролетариатның гомуми сыйнфи интересларына бик нык буйсындырылган мәсьәлә дип карый... „милли интереслар" һәм „милли таләпләр" дип аталган нәрсәләрнең, **үзләренә аерым алынганда,** бернинди кыйммәтләре юк,... бу „интереслар" га һәм „таләпләр" гә пролетариатның сыйнфи аңын, аның сыйнфи үсешен аларның никадәр алга таба алып баруларына яки алып бара алуларына карап кына игътибар бирелергә тиеш" (шунда ук, бит 61).

Иптәш Сталин, милли мәсьәләне хәл итү бары тик революция юлларында гына мөмкин, бары тик буржуазиянең политик өстенлеге бетерелгәндә генә мөмкин икәнлекне аеруча күрсәтә. Ул болай дип язды: „... Гомумән әйткәндә, политик өстенлек буржуазия кулында булган вакытта „милли мәсьәлә"не „тәмам" хәл итү, ягъни Россиядәге „чит" милләтләрне „азат итү" мөмкин түгел" (шунда ук, бит 64).

Иптәш Сталин милли-азатлык хәрәкәтләренә, аларны яклау турындагы мәсьәләгә дә пролетариатның сыйнфи интереслары күзлегеннән карады.

Иптәш Сталин болай дип язды:

„Шундый экономик һәм политик шартлар туарга мөмкин ки, бу шартларда „чит" милләтләр буржуазиясенең алдынгы даирәләре „милли азатлык" теләячәкләр.

Шулай ук, мондый хәрәкәтнең пролетариатның сыйнфи яктан үзен аңлавын үстерү өчен дә файдалы булып чыгуы мөмкин" (шунда ук, бит 65).

Һәм аннары: „Билгеле, бу мәсьәләне хәл итүне „чит" милләтләрнең үзләренә тапшырырга кирәк, ә без аларга бу мәсьәләне хәл итү хокукын яулап алырга тиешбез. „Милли бәйсезлек" нең үзләре өчен файдалымы яки зарарлымы икәнлеген һәм әгәр файдалы булса—ул чагында аны нинди формада тормышка ашырырга кирәклекне милләтләр үзләре, кирәк чагында хәл итсеннәр. Бу мәсьәләне алар гына хәл итә алалар!" (шунда ук, бит 66).

Иптәш Сталин 1904 нче елгы мәкаләсендә үк инде милли мәсьәлә буенча большевизмның барлык 4 программ положениесен күтәрде, соңрак бу положениеләр большевистик партиянең милли мәсьәлә буенча киң программасының нигезе булып әверелделәр.

Иптәш Сталин бу мәкаләсендә үк инде милләтләрнең үз билгеләнү, тулысынча аерылып чыгу хокукларын күздә тотты. Иптәш Сталин асылда бу мәкаләсендә үк инде бер дәүләт чикләрендә калучы милләтләр өчен өлкә автономиясе турындагы мәсьәләне куя.

Шул ук мәкаләсендә иптәш Сталин милләтләрнең тигез хокуклы булулары турындагы, халыкларга иркле милли үсеш гарантиясе турындагы—ана теленнән, ана телендә укыта торган мәктәпләрдән файдалану, үзләренең милли культураларын үстерү хокуклары һ. б. турындагы мәсьәләне куя. Иптәш Сталин болай дип язды: „... Үзебезнең барлык көчләребез белән без Россиядәге милләтләрнең граждандык ягыннан тигез хокуклы булулары өчен көрәшәбез һәм көрәшәчәкбез" (шунда ук, бит 61).

Иптәш Сталин бу мәкаләсендә үк инде барлык милләтләрнең эшчеләрен интернациональ туплау принципын, Россиядәге барлык милләт эшчеләр сыйнфының бердәм, үзәкләштерелгән партиясен төзү өчен көрәш принципын алга куйды.

Иптәш Сталин болай дип язды:

„... Безгә бердәм, нык, үзәкләштерелгән партия кирәк, аның Үзәк Комитеты Бөтен Россиядәге эшчеләрне күз ачып йомганчы аякка бастыра алыр һәм аларны самодержавиегә һәм буржуазиягә каршы кискен штурмга алып бара алыр..." (шунда ук, бит 60).

Моның өчен Россиядәге барлык милләтләрнең эшчеләрен интернациональ туплау, милли киртәләрне җимерү таләп ителә.

Иптәш Сталин болай дип язды:

„Россиядәге пролетарийларны бер-берсенә яхшырак якынайту өчен, аларны тазарак туплау өчен, милләтләр арасына корылган милли киртәләрне ничек җимерергә, милли аерманы ничек бетерергә?

Социал-демократиядә „милли мәсьәлә" нең мәгънәсе әнә шул" (шунда ук, бит 58).

Иптәш Сталин Грузия федералистларын рәхимсез рәвештә фаш итә. Федералистлар, Бунд кебек үк, партияне милли билгеләр буенча төзергә, ә аннары инде шушы аерым, таркау, милли партияләрнең союзын (федерациясен) төзергә тәкъдим иткәннәр иде.

Иптәш Сталин, партияне бу рәвештә төзүнең эшчеләрнең интернациональ бердәмлеген җимерүгә, милли киртәләрне ныгытуга, төрле милләтләрнең эшчеләрен аерылышуга гына китерүе мөмкинлекне һәм боларның буржуазиягә һәм самодержавиегә файдалы икәнлеген күрсәтте. Федералистларча эшләгәндә без **милли киртәләрне җимерү** урнына, аларны организацион киртәләр белән **тагын да ныгытыр** идек; пролетариатның сыйнфи аңын **алга алып бару** урнына, без аны **артка алып ташлар** идек һәм куркынычлы сынауларга дучар итәр идек" (шунда ук, бит 60).

Партияне бу рәвештә оештырганда пролетариат белән буржуазия арасындагы сыйнфи аермалар капланып калалар, сыйнфи көрәш милли көрәш белән алмашына, „сыйнфи татулык" өчен җирлек туа. Иптәш Сталин болай дип язды: „Моннан, бергәләшеп хәрәкәт итү җирлегенә" дә ерак калмый, буржуа да, пролетарийлар да шул җирлеккә басарга һәм бер үк „милләт" членнары сыйфатында бер-беренә кул сузарга тиеш булалар" (шунда ук, бит 59—60).

* * *

Закавказьедәге революцион марксистларны Ленин — Сталинның интернациональ байрагы астына туплауда „Милли мәсьәләне социал-демократия ничек аңлый?" дигән мәкалә гаять зур роль уйнады.

Иптәш Сталин мәкаләсенең әһәмияте болар белән генә чикләнми. Мәкалә, милли мәсьәлә буенча большевистик программаның һәм тактиканың нинди дошманнарга каршы көрәштә төзелгәнлекләрен күрсәтә, һәм шуңа күрә дә аның милли мәсьәлә буенча партия программасының килеп чыгу һәм үсү тарихын өйрәнү өчен дә зур әһәмияте бар.

Иптәш Сталин тарафыннан инде моннан 35 ел элек билгеләнгән принциплар, социалистик илебездә тулысынча тормышка ашырылдылар һәм бөек Сталин Конституциясендә алтын хәрефләр белән язылдылар.

А. Пясковский.

ЧАПТЫРУ КАМПАНИЯСЕ ҺӘМ ЯҢА БУРЫЧЛАР

Хәзер Татарстан колхозларында һәм совхозларында атларны чаптыру кампаниясе массовый күләмдә башланды. Чаптыру кампаниясе атлар санын арттыру эшендә гаять зур урын тота. Аны уңышлы үткәрү белән без үз игтибарыбызны партиянең XVIII нче съезды куйган бурычны—өченче бишьеллыкта атлар санын 35 процентка арттыру бурычын үтәүгә юнәлдерәбез.

Үткән ел чаптыру кампаниясе начар үтте. Бияләрне каплату буенча дәүләт планы бары 90,3 процентка, метислаштыру планы 85,8 һәм бияләрне ясалма орлыкландыру планы 79,8 процентка гына үтәлде.

Аерым районнарда бу кампания тагын да начар үтте. Мәсәлән, Апас районында бияләрне каплату планы 80,2 процент белән, ясалма орлыкландыру—24,6 процент белән калды. Мамадыш районында каплату планы 71,9 проценттан да артмады.

Атларны чаптыру кампаниясе һәм метислаштыру планнарын үтәмәүнең төп сәбәпләре атларның колхоз производствосында һәм оборона эшендә тоткан әһәмиятенә бәя биреп җиткермәүдән килә.

Атларга яхшы караш булган һәм аның әһәмиятен аңлаган урыннарда эш бөтенләй башкача тора. Атчылык хуҗалыгы зур адымнар белән алга бара. Мисаль итеп берничә колхозның атчылык фермаларын гына алыйк.

Азнакай районы, „Герой труда“ колхозының товарлыклы-атчылык фермасы (мөдире Әхмәт иптәш Фәйзуллин) тулы планын ел саен тулы үти. 1937—38 нче елны анда һәр 100 биядән 92,5 колын алынды һәм үстерелде. Ферма 1939 нчы елны да 100 баш биядән 85 колын алып үстерде.

Саба районы, „Кызыл юл“ колхозының ат караучысы иптәш Камалов Гыйлми 1938 нче елны үзе тәрбияли торган 20 биядән 19 колын, 1939 нчы елда 18 биядән 18 колын алып үстерде.

8 нче мартта өлкә газеталарында ВКП(б) Үзәк Комитетының һәм СССР Совнаркомының **„Авыл хуҗалыгы продуктлары хәзерләү һәм сатып алу политикасында үзгәрешләр“** турындагы карары басылып чыкты. Бу аеруча әһәмиятле, колхоз строен үстерү интересларын күз алдында тота торган карар атчылык эшен күтәрүгә, аерым алганда чаптыру кампаниясен уңышлы үткәрүгә гаять зур этәргеч ясарга тиеш һәм ясаячак.

Ул карарда болай диелгән:

„Колхозларга беркетелгән җир мәйданына (сөрү җиренә, шул исәптән җимеш һәм түтәл бакчаларына, болыннарга һәм көтүлекләргә) карап, армия өчен яраклы булган югары сыйфатлы атлар үрчетү һәм үстерү буенча барлык колхозлар өчен мәҗбүри минимум билгеләргә. 1941 нче елдан башлап билгеләнгән минимум атлар санына туры китерелгән нормалар буенча оборона кирәкләре өчен мәҗбүри рәвештә ат тапшыру тәртибен кертергә“.

Карар бик ачык, бик аңлаешлы. Моннан соң, атчылык эшен яхшы куйган колхозлар тагын да яхшырачак. Бу карар нигезендә, ат фермалары булмаган колхозлар да оборона кирәкләре өчен ат тапшырырга тиеш булалар. Бу закон шул турыда сөйли. Димәк, һәрбер колхоз ат турында, аны үрчетү, аны үстерү турында нык кайгыртырга тиеш була.

Чаптыру кампаниясен үткәргәндә бу яңа законны, бу яңа тәртипне истә нык тотарга кирәк. Чөнки чаптыру кампаниясе ул атлар санын үрчетү эшендә хәл иткеч момент булып санала. Үткән еллардагы ялгышларны һич тә кабатламаска кирәк.

Бияләрнең барсын да зоотехника - ветеринария комиссияләре аркылы үткәреп, каплатылырга тиешле бияләрне учетка алырга кирәк.

Һәрбер колхозның чаптыру пунктына иң яхшы колхозчыны мөдир итеп билгеләргә кирәк. Үрчеткеч айгырлар яхшы тәрбиядә торырга, аларның спермлары әледән-әле тикшерелеп торырга тиеш.

Каплату өчен маглүм санда бияләр беркетү үрчеткеч айгырның көченә һәм торышына карап эшләнергә тиеш. Табигый каплатуда тулысынча таза канлы үрчеткеч айгырлардан 40—60 бия каплатыла. Ясалма орлыкландыруда 150 дән алып 200 гә чаклы бия, ә яш үрчеткечләрдән (3 яштән ким) һәм карт үрчеткечләрдән 15—25 бия каплатыла.

Үрчеткеч айгырлар яхшы, якты абзарларда торырга, яхшы тукландырылырга тиешләр. Чаптыру кампаниясе өчен билгеләнгән үрчеткечләрне авыр эшләргә һәм ерак юлларда йөрү өчен файдаланучыларга каршы иң каты көрәш алып барылырга, үрчеткечләрне авыр эштә йөртеп бозучылар каты җавапка тартылырга тиешләр.

Бездә яхшы нәселле үрчеткечләр күп. 1939 нчы елны гына да яхшы нәселле 336 баш үрчеткеч айгыр кайтартылды. Бурыч—бу үрчеткечләрдән тулы файдаланудан һәм метислаштыру планын арттырып үтәүдән гыйбарәт.

Югары бәяле нәсел үрчеткечләрдән тулы файдалану һәм алардан яхшы нәселле колыннар булдыру өчен Татарстанда 90 урында бияләрне ясалма орлыкландыру пунктлары бар. Аларда 13 мең бия орлыкландырылырга тиеш. Бурыч зур һәм җаваплы. Зоотехниклар һәм ветработниклар бу пунктларда эшләүчеләргә якыннан торып ярдәм итәргә тиешләр.

Быел атларны чаптыру кампаниясе планы тулысынча үтәлергә тиеш. Армия өчен яраклы атлар тапшыру турындагы яңа закон, яңа тәртип һәм колхоз интереслары әнә шуны таләп итәләр.

М. Бакаев.

Татнаркомземның атчылык управлениесе начальнигы.

ТАТАРСТАННЫҢ XX ЕЛЛЫГЫ АЛДЫННАН

КВАРТАЛ ПЛАНЫ АРТТЫРЫП ҮТӘЛДЕ

Ленин исемендәге заводның столярно-пояльный цех коллективы ярты еллык планны 25 нче июньгә—республикабызның XX еллык бәйрәменә 120 процент итеп үтәү йөкләмәсен алган иде. Бу йөкләмә практик эш белән ныгытыла.

Ярышның беренче нәтиҗәләре язу алдында. Беренче квартал планын цех коллективы арттырып үтәде. Иптәш Строительев җитәкчелегендәге мастерской квартал планын 166,9 процент итеп, иптәш Буров җитәкчелегендәге мастерской 127,3 процент итеп үтәде.

Ф. Абзалов.

ДОНБАСС ШАХТЕРЛАРЫ ЯРЫШЫ

Орденлы Татарстан республикасының меңнәрчә колхозчылары Донбасс шахталарында эшлиләр. Монда хәзер Татарстанның XX еллык юбилеена хәзерлек эшләре киң җәелдерелде. Шахтерлар коллективы данлыклы юбилейне хезмәт җитештерүчәнлеген тагын да күтәрү белән, һәм планнан тыш меңнәрчә тонна күмер бирү белән каршылау өчен көрәшә.

Йөкләмәләр эш белән ныгытыла. Мәсәлән, „Ворошиловуголь“ трестының икенче номерлы шахтасында ТАССР ның XX еллыгы исемендә оештырылган бригада (бригадиры ВКП(б) кандидаты иптәш Гадеев) айлык план үтәлешен 130—150 процентган киметми. 25 нче номерлы шахтада да социалистик ярыш киң колач алды. Десятник, комсомолец иптәш Гыйлметтинев тарафыннан җитәкчелек ителә торган смена коллективы аеруча яхшы эшли. Бу смена тәүлегенә 160 тонна күмер чыгару планын 270—280 тонна итеп үти, 13 нче лаванын атаклы разбуровщигы иптәш Сабитов үзенә нормаларны яхшы үзләштереп, хезмәт җитештерүчәнлегенең югары күрсәткечләрен бирә. Шахта коллективы ТАССР ның XX еллыгына бүләк итеп, 2 нче квартал планын 25 нче майга үтәү өчен көрәшә.

Нуреттинов.

КОМПЛЕКСЛЫ БРИГАДА

14 нче төзү трестының 3 нче төзү участкысында март аенда ташчылардан, балта осталарыннан һәм ярдәмче эшчеләрдән комплекслы бригада оештырылган иде. Бу бригада 18 нче „А“ нчы төзелешендә 300.000 данә кирпеч салып, март ае планын 200 процентган да арттырып үтәде һәм бу портта кирпеч салу эшен тәгәлләде.

Комплекслы бригадада эшләгән ташчылардан күпчелеге хезмәт җитештерүчәнлеген бер ярым—ике тапкыр арттырдылар. Ташчы иптәш Жуков февраль аенда планны 133 процент итеп үтәгән булса, март аенда 203 процент итеп үтәде. Иптәш Галиәскәров март ае планын 220 процентган да арттырып үтәде.

Бригадир иптәш Шәһвәлиевнең хезмәтне дөрес оештыруы нәтиҗәсендә, бригада членнары арасында эшсез торулар бөтенләй бетерелде.

Комплекслы бригада төзелештә яңа кадрлар хәзерләү эшендә дә зур әһәмият бирә. Хәзер бригадада 14 өйрәнчек бар. Бригада членнары бу өйрәнчекләрне Татарстанның XX еллыгына кадәр квалификацияле ташчылар итеп хәзерләп чыгару өчен көрәшәләр.

З. Гәрәй.

Юдино исемендәге клубның (Юдино станциясе) уку залында эпохабызның иң талантлы шагыйре В. В. Маяковскийның үлүенә 10 ел тулуга багышланган күргәзмә оештырылды. Рәсемдә: күргәзмәгә килүчеләр экспонатларны карыйлар.

Б. Невзоров фотосы.

ТӨЗЕК ҺӘМ КУЛЬТУРАЛЫ ЮЛЛАР ӨЧЕН

Юллар төзелеше сезонына хәзерлек чоры нигездә тәмамланды. Тагын бер айдан республикабызда юллар төзелеше эшләре җәелдереләчәк. Бу сезонга хәзерлек эше ничек соң?

Халык хуҗалыгының әһәмиятле тармакларының берсе булган юллар төзелешенә быелгы сезонга хәзерлек эшенә чынлыктан тотынган һәм бу эшкә җитәкчелекне партия, совет оешмалары үз кулларына алган урыннарда эш, әлбәттә, яхшы бара. Мәсәлән, Бондюг (район юл бүлеге мөдире иптәш Шәймәрданов), Арча (район юл бүлеге мөдире иптәш Зарифуллин), Ютазы (район юл бүлеге мөдире иптәш Шамгуллин) һәм Буа (район юл бүлеге мөдире иптәш Гыйлметтинев) районнары социалистик ярышта алган йөкләмәләрне намус белән үтәделәр. Төзелеш сезонына тулы хәзерлекне тәмин итәләр. Алар төзү материаллары хәзерләү һәм аны эш объектларына ташу планнын арттырып үтәделәр.

Кызыл Армия һәм Яңа Чишмә районнарында да быел төзелеш сезонына хәзерлек эшләре үткән елларга караганда күп яхшы барылды. Дәүләт үз вакытында яңа юллар төзекләндерү эшенә соралган төзү материаллары хәзерләү планы бу районнарда тулысынча үтәлде.

Казан—Чистай—Бөгелмә трактын төзекләндерү эшендә Фергана тәҗрибәсен куллану турында Столбище районының „13 лет Октября“ колхозчылары мөрәҗәгате Кызыл Армия районында һәрбер колхозчыга җиткерелде. Юллар төзелешенә ярдәм күрсәтү буенча ВКП(б) райкомы янында оештырылган махсус комиссия (председателе иптәш Закиров) бу эшкә оператив җитәкчелек итә. Комиссия членнары трасса белән, эш объектлары белән якыннан таныштылар, юл төзелеше работникларына практик ярдәм оештырдылар. Партия активының 26 кешесе аерым колхозларга беркетелеп, алар анда эшне оештыручы булдылар. Авыл советы башкарма комитеты председательләреннән 4 кеше эш объектларына турыдан-туры үзләре җитәкчелек итәләр. Районда узган елны беренче апрельгә кадәр 1.120 кубометр төзү материаллары хәзерләнгән булса, быел ул 2.350 кубометрга җитте. Төзү материаллары хәзерләүдә һәм аларны эш объектларына ташуда һәр көнне уртача 200—250 кеше һәм 120—130 ат эшләде. Кызыл Армия районы Чистай белән ярышта җиңеп чыкты. Район территориясендәге 12 километр юлны төзекләндерү өчен ныклы база хәзерләнде.

253 нче номерлы юл төзелеше участкысының мактаулы мастеры иптәш Мотыйгуллин тарафыннан җитәкчелек ителә торган 4 нче дистанция (Яңа Чишмә районы) 1.490 кубометр урнына 1.795 кубометр төзү материаллары ташып, планны 120 процент итеп үтәде һәм участкыларда беренче урыны яулап алды. Моңдый алдынгыларны күп күрсәтергә мөмкин.

Ләкин төзелеш сезонына хәзерлек эшенең гомуми торышы республикабызда һич канәгатьләнерлек түгел. Төзү материаллары хәзерләү һәм аларны эш объектларына ташу планы бары 32 процентка һәм дәүләт юлларны төзекләндерү өчен бирелгән планы 67,9 процентка гына үтәлде. Байтак кына районнарда юл төзелешенә икенче дәрәҗәдәге эш дип карау дәвам итә.

Моны раслау өчен Столбище, Лаеш, Алексеевский һәм Чистай районнарын алу да җитә. Монда практик юл корылышына җитәкчелек итү юлчылары белән, йөкләмәләр алу белән генә чикләнгән. Юл төзелешенә ярдәм күрсәтү буенча ВКП(б) райкомнары янында оештырылган комиссияләр үз бурычларын аңлап җитәрлек эшләмиләр. Нәтиҗәдә, бу районнар юл төзелешендә зур хурлыклы рәвештә коерыкта сөйрәләләр. Төзү материаллары хәзерләү планнары үтәлеше 20—30 проценттан артмый.

Чистай, Алексеевский, Лаеш һәм Столбище районнарында юл төзелеше сезонына хәзерлек эшенең өзелү куркынычы тудырыла, шуңа күрә колхоз председательләрен бу өлкәдә эшләүдән ачыктан-ачык баш тартулары, сабоктажлык күрсәтүләре турында матбугатта сигналлар да булмады. Ләкин район җитәкчеләре бу сигналларга үз вакытында игътибар итмәделәр, киресенчә, булган җитди кимчелекләрне томалап калу юлына бастылар. Ә бит бу районнар юл төзелеше планын елдан-ел өзеп киләләр. Шуның өчен дә бу район җитәкчеләренә карата тиешле чаралар ясарга, алардан дәүләт планын үтәүне катгый рәвештә таләп итәргә вакыт җитте.

Эшнең бу кадәр хурлыклы рәвештә артта калуы өчен Татарстан Совнаркомы янындагы юллар идарәсе (начальнигы иптәш Синявский) җитәкчеләре дә гаепле. Чөнки алар эш участкыларына оператив җитәкчелек итмиләр, тегә яки бу таркакта эшне юлга салу өчен тиешле чаралар күрмиләр. Район юл бүлекләренә җитәкчелек итү сводкалар язу белән генә чикләнгән, соңгыларның үтәлешен тикшерү ягы бөтенләй онытылган. Мамадыш районы юл бүлеге мөдире Николаев, Столбище районында Калафатова һәм юл станциясе директоры Теплов булдыксызларга бер кем тарафыннан да җил тими. Монда объектив сәбәпләр артына яшеренеп, эшне юлга салмаучыларга Татарстан Совнаркомы кызыксынмый, эшнең чын торышына большевистик нәтиҗә ясарга тиеш.

Төзелеш сезоны башлануга күп калмады. Бу санаулы көннәрдән тулы файдаланырга, бөтен эчке мөмкинлекләрне тупларга, дәүләт планын һич сүзсез үтәү өчен барлык чараларны күрергә кирәк.

Ким Биков.

ЭПОХАБЫЗНЫҢ ИҢ ТАЛАНТЛЫ ШАГЫЙРЕ

(В. В. Маяковскийның үлүенә 10 ел тулуга карата).

Владимир Владимирович Маяковскийның гомере кыска булды. Ул 1893 нче елны туды. 1912 нче елны яза башлады. 1930 нчы елны инде аның гүзәл тормыш юлы өзелде.

Маяковскийның тормышы вакыт ягыннан кыска иде, ләкин чиктән тыш тулы һәм киеренке булды. Ул гаять зур һәм рухланган хезмәт белән, кыю һәм бөек иҗад эзләнүләре белән тулган иде.

Күп кенә күренекле рус язучылары кебек үк, Маяковскийны да тормыш үзе революционер итте. А. М. Горький үзенең марксизмны китаплардан укудан элек (аның революцион аңын тәмам төзеп җиткерүчеләр шул китаплар иде) тормышның үзеннән, патша Россиясендәге халыкның тормышыннан, коллык һәм каторга тормышыннан, ләкин шул ук вакытта протест һәм көрәш рухы белән, массаның үлмәслегенә һәм изүчеләрне җиңүенә булган ышанычы белән сугарылган тормыштан өйрәнгәнлеген әйтергә ярата иде. Маяковский да үзенең үткән юлына карап, үләр алдыннан язган шигырендә, „Бөтен тавыш белән“ дигән поэтик васыятендә үзе турында һәм үз буыны кешеләре турында, революциябезнең сугышчылары турында сөйләгәндә шуның шикеллерәк бер фикер әйтте.

Маяковский Грузиядәге бер авылда туып үсте. Аның балалык еллары гүзәл табигать шартларында, ярлы крестьяннәр арасында, гади, кыю һәм көчле, ләкин самодержавиенең һәм капитализмның газаплы һәм рәхимсез изүе астында җәфа чиккән кешеләр арасында үтте.

Кимсетелгәннәргә карата мәхәббәт һәм аларны кызгану, аларга тирән һәм чын якынлык хисләре—Маяковскийда бу хисләр бик иртә уяндылар. Алар беренче рус революциясе заманнарында өлгереп җиттеләр.

Маяковский беренче тапкыр нак менә 1905 нче елны үзен революциянең актив катнашучысы итеп сизде. Истәлекләрнең авторлары Кутаиси гимназиясе (ул чагында забастовка ясаган гимназия) укучысы, Багдадидагы урман каравылчысы улы—12 яшьлек Владимир Маяковскийның революцион демонстрантлар белән берлектә, грузин революционерлары җырларының һәм гимннарының өндәүле сүзләрен кычкырып, Кутаиси урамнары буйлап үткәнлеген язалар.

1905 нче елдан соң ук, революцион хәрәкәтнең вакытлыча җиңелүенә дә карамастан, Маяковский үзен революция эшенә багышларга карар бирә. Ул, яшьләрнең революцион оешмалары аркылы үтеп, большевиклар партиясенең Москва комитетына мөрәҗәгать итә һәм пропагандист булып эшләргә бара. „Константин иптәш“ (Маяковскийның партия кушаматы шул иде) большевистик тактиканы чын күңелдән яклаучы гына түгел, бәлки заманына күрә бик белемле марксист-теоретик та иде. Ул Маркснын „Капитал“ ын, Лениннең „Ике тактика“сын, Плехановның „Тарихка монистик карашның үсеше турындагы мәсьәләгә карата“ дигән китабын һәм берничә дистәләрчә революцион брошюраларны белә иде. Подпольече яшь большевикның революцион эшен озак та үтми патша шпионнары сизеп алдылар һәм „высокий“ (охранканың агентура сводкаларында Маяковский шул исем астында йөртелә иде) моның өчен төрмәдә өч өлеш артык утыру җәзасын алды. Яшь Маяковскийга самодержавиенең полиция режимының барлык „матурлыкларын“ күрергә туры килде: аны допросларга йөрттеләр, бер участкыдан икенчесенә, бер төрмәдән икенче төрмәгә күчерделәр, үзенең рәхимсезлеге белән атаклы булган Бутырки төрмәсендә ул ялгыз камерада газапланды, ике тапкыр суд алдына басты.

Ләкин революцион иҗад эшенә омтылыш яшь бунтарьда тагын да күбрәк ныгыды гына. Төрмәдән ул шагыйрь һәм художник булырга дигән ныклы карар белән чыкты. Ул халыкка хезмәт итеп сәнгаткә хезмәт итәргә теләде. Ул язучылар арасына „Социалистик сәнгат ясарга телим!“ дигән яхшы лозунг белән килде. Маяковский үзенең әдәби юлының Октябрьгә кадәрге беренче бишьеллыгында ук инде иң күренекле шагыйрь булып үсте. Шул чагында ук инде ул үзенең сәнгатен халык сәнгате итәргә, анарда күп миллионлы массаның капиталистик эксплоатациягә һәм алпавытларның изүенә каршы ачуын һәм протестын чагылдырырга омтылды. Ул чагында әле тәмам өлгереп җиткән пролетар революционер булмаса да, Маяковский шундый революционер булырга бик нык теләп, киң һәм ышанычлы адымнар белән пролетариатның алдынгы идеяләрен һәм аның көрәш принципларын аңлауга таба барды. Туган иленең язмышы турында һәр вакыт борчылып, ул аның киләчәген төшенергә тырышты, алга таба, иртәгәге көнгә ачык күз белән карады һәм революциянең тиздән җиңәчәген шатлык белән алдан әйтеп куйды.

Аның революциягә кадәрге барлык шигырьләре капитализмга каршы протест темасы белән сугарылган. Яшь Маяковскийның поэзиясе кешенең азатлыгы өчен, хезмәт һәм иҗад кешеләренең тантанасы өчен бунт иде. Ул лирик шигырьләрдә дә, „Владимир Маяковский“ трагедиясендә дә, көлке памфлетларында да, „Штанлы болыт“ һәм „Сугыш һәм солых“ поэмаларында да капитализмга каршы кыюлык белән сугышка ташланып, аның кешене дошман күрүчәнлек табигатен фаш итте.

Моның өчен патша цензурасы аны рәхимсез өзәрләкләде. Аның шигырьләреннән патшага каршы бунтка турыдан-туры өнди торган барлык урыннар сызып ташландылар. Аның „Штанлы болыт“ поэмасын цензура теткәләп бетерде. Бары тик Маяковский поэзиясенең үсешен мәхәббәт белән күзәтеп килгән Горький гына Маяковскийның беренче бөтен дөнья империалистик сугышына каршы юнәлдерелгән „Сугыш һәм солых“ дигән поэмасыннан бер бүлекне генә басып чыгара алды.

Бөек Октябрь Социалистик революциясе Маяковский алдында гаять киң иҗад перспективалары ачты. Аның турында шагыйрь „Минем революциям“ дип горурлык һәм шатлык белән әйтте. Шунда ук ул „революция тарафыннан мобилизацияләнгән һәм чакырылган“ солдат буларак, аның интересларына хезмәт итү юлына басты. Революция аркасында ул үзенең ватанын тапты, аңа үзенең барлык көчен, барлык талантын бирде, аның турында күтәрелеп һәм рухланып җырлады.

Хәрби коммунизмның героик елларында ул ватанны саклауга хезмәт итте (агиткалар, сатира тәрәзәләре, „Сәнгат армиясе буенча приказлар“) һәм безнең революциябезнең бөек колачын художество образларында гәүдәләндерде („Мистерия—Буфф“, „150.000.000“). Аның революциядән соңгы поэзиясендә элекке иҗадының трагик мотивлары инде бөтенләй юк иде.

Маяковский революциянең беренче елларында ук, социалистик ватанның бөек шагыйре булып әверелде. Аның „В. И. Ленин“ һәм „Яхшы!“ дигән онтылмаслык поэмаларында, „Өйгә!“ шигырендә һәм „Совет паспорты турында шигырьләр“ дә гәүдәләнгән совет патриотизмы, социалистик гражданлык хисләре тууын Маяковский үзе дә безнең революциябезнең беренче елларына кайтарып калдырды.

Маяковскийның органик революцион патриотлыгы аны гаять күренекле политик шагыйрь-агитатор итте. „Агитаторлык, акыручылык, гловарьлык“ буенча үзенең эшен Маяковский көн саен иҗад итте, үткен сатиралы агитфельетоннар, күңелле маршлар һәм лозунг-приказлар тудырды. Бюрократизмга каршы юнәлдерелгән, „Утырыштан башканы белмәүчеләр“ дигән гүзәл шигыре уңае белән Ленин аңа бик югары бәя бирде. Маяковскийның агитация эше зур принципиаль идеялелеккә нигезләнгән иде, ул хәзерге заманның шагыйрь тарафыннан ачылган иң әһәмиятле идеологик проблемаларына нигезләнгән иде. Нак менә шуңа күрә дә ул үзенең җиңүчән агитацион көченә ирешә алды. Һәр вакытта да агитатор булып каларак, Маяковский үзенең иҗадында иң нечкә лиризмга да барып җитә алды. Яңа гуманизм идеясенә ул гаять зур әһәмият бирде. Ул бу идеяне „Владимир Ильич Ленин“ поэмасында гүзәл төстә эшләде. Анда ул Ленин турында язып, социалистик гуманизм идеяләрен һәм хисләрен ачык чагылдыручыны күрсәтте. „Шушы турыда“ дигән гүзәл поэмасында, совет поэзиясенең бурычлары турындагы лирик, программ шигырьләрендә Маяковский яңа кешене, совет кешесен тиңдәшсез зур көч белән күрсәтте.

Маяковскийның поэзиясе, аның „йөз том партия кнәгәләре“, искермичә, яшиләр һәм массаны өйрәтәләр, коммунизм рухында тәрбиялиләр. Алар—большевистик тәрбия коралы.

Маяковскийның „һөҗүм итүче сыйныфка“ биргән сүзе элеккечә сугышчан өндәү булып яңгырый. Ул бөек шагыйрьнең китапларында, газеталарыбызның баш мәкаләләрендә, тарихи халык собраниеләре трибуналарында көрәшкә өндәү булып яңгырый. Без аны большевистик „Правда“ мәкаләләрендә еш очраттык, ул партия съездлары делегатларының речьләрендә матур һәм көчле булып яңгырый.

Маяковский—совет халкының яраткан шагыйре. Ул аның шагыйре булды һәм шулай булып кала.

Аның патриотик поэзиясенең оборона өлкәсендә әһәмияте гаят зур. Ул совет кешеләрен үзләренең каннарын һәм тормышларын кызганмыйча бөек һәм сөекле Ватанга хезмәт итәргә өйрәтә.

Маяковский—совет поэзиясенең иң күренекле, тиңдәше булмаган мастеры. Ул совет сәнгатенә искиткеч поэзия байлыклары биреп кенә калмады, бәлки иң яхшы совет шагыйрьләренең иҗады өчен нигез булырлык поэтик билгеләүләр дә бирде. Аның тирәнтен партиячә һәм халыкча булган поэзиясе сугышчан партиялелекнең киң җәелгән байрагы астында үсте.

Чит илләрдә

Германия хөкүмәтенең меморандумы

БЕРЛИН, 9 апрель. (ТАСС). Германия информация бюросы Германия хөкүмәтенең Дания һәм Норвегия хөкүмәтләренә биргән меморандумынын текстын тапшыра. Меморандумда болай диелә: „Германия халкынын һәм анын хөкүмәтенең Англия һәм Франция халыклары белән тату һәм дус яшәүгә чын күңелдән омтылуларына да карамастан һәм кара каршы бәхәсләшү өчен бер нинди дә төпле нигез булмауга да карамастан Лондонның һәм Парижның хуҗалары Германия халкына сугыш иглан иттеләр. Германия империясенең хокукларына һәм Германия халкының яшәвенә каршы үзләре тарафыннан күптән хәзерләнеп килгән агрессив сугышны җәеп җибәреп, Англия һәм Франция бер үк вакытта нейтраль илләргә каршы диңгез сугышы ачтылар. Шушы сугыш ярдәме белән алар, халыкара хокукны бөтенләй игтибарсыз калдырып, Германия хатын-кызларына, балаларына һәм картларына каршы ачлык блокадасын тормышка ашырырга маташтылар. Блокаданы тормышка ашыру буенча аларнын рәхимсез чаралары нейтраль илләргә карата да кулланылды. Көрәштә Англия һәм Франция тарафыннан кулланылган һәм халыкара хокукка капма-каршы килә торган шушы методларның турыдан-туры нәтиҗәсе нейтраль илләрнең пароход йөртүләренә һәм сәүдәләренә авыр зиан китерүдән гыйбарәт. Германия бу методларга каршы оборона чаралары белән җавап бирергә мәҗбүр. Шуның өстенә Англиянең бу чаралары нейтралитет дигән төшенчәнең үзенә дә җимергеч удар ясадылар. Германия диңгез сугышын Германия белән аның дошманнары арасындагы зоналар белән чикләргә тырышып, нейтраль илләрнең хокукларын тәэмин итәргә омтылды. Англия, киресенчә, үз атауларына булган куркынычны бетерү һәм шул ук вакытта Германиянең нейтраль илләр белән сәүдәсенә тоткарлык ясау өчен диңгез сугышын торган саен нейтраль илләрнең суларына күчерә барды. Сугышны алып баруда нак Британиячә булган шушы методны кулланып, Англия халыкара хокукны бозып, үз суларында, шулай ук Дания һәм Норвегия территорияләрендә диңгез һәм һава сугышын торган саен җәелдерә барды. Вакыйгаләрнең болай булуы мөмкинлеген Германия сугыш башланганда ук белгән иде. Германия үзенең эчке һәм тышкы экономик политикасын тормышка ашырып, англичаннарның Германияне ачлык блокадасы белән нейтраль илләрдән аерырга маташуына комачаулый алды. Соңгы айларда Британиянең Германияне блокадалау политикасының тәмам җимерелгәнлеге торган саен ачык күренә барды. Вакыйгаләрнең болай баруы, шулай ук Германиянең көнбатыштагы ныгытмалары линиясенә турыдан-туры һөҗүм ясауның мөмкин булмавы һәм диңгездә дә, һавада да Германиянең унышлы контратакалары уңае белән Англиядә һәм Франциядә борчылуның торган саен үсә баруы соңгы вакытларда бу ике илнең сугыш мәйданын Европада да, шулай ук, Европадан тышта да барлык чаралар белән нейтраль территориягә күчерергә маташуларына китерде.

Билгеле, Англиянең һәм Франциянең Европадагы кечкенә дәүләтләрнең территорияләреннән файдаланырга уйлаулары Англиянең традицияләренә туры килә. Соңгы айларда Англиянең һәм Франциянең дәүләт эшлеклеләре үзләренең сугышны бу өлкәләргә җәелдерү планнарын ачыктан-ачык иглан иттеләр. Аларның төп стратегик максатлары шунда иде. Рус-фин конфликты моңа беренче сылтау булды Англия һәм Франция хөкүмәтләре үзләренең Финляндия белән Советлар Союзы арасындагы конфликтка сугыш юлы белән катнашырга һәм шулай итеп операцияләрне җәелдерү өчен төньяк илләрне база итеп файдаланырга уйлауларын ачыктан-ачык белдерделәр. Англиянең һәм Франциянең теләгенә каршы килеп һәм алар көтмәгәндә генә төньякта төзелгән солых аларга шул вакытта ук инде үзләренең карарларын үткәрүгә комачаулады.

Әгәр дә Англиянең һәм Франциянең дәүләт эшлеклеләре соңыннан инде бу адымны тиешле дәүләтләрнең ризалыгына карап атларга теләгәнлекләрен белдергәннәр икән, бу тупас ялган. Англиянең һәм Франциянең төньяк дәүләтләр территориясендә үзләренең максатларын аларның ризалыгыннан башка бергәләп тормышка ашырырга карар биргәнлекләре турында Германия хөкүмәте кулында документаль дәлилләр бар. Ләкин иң әһәмиятлесе менә нәрсәдә: Германия хөкүмәте кулында булган маглүматларга караганда, Совет—Финляндия солых договорына кадәр дә һәм аннан соң да Франция һәм Англия хөкүмәтләренең позицияләреннән күренгәнчә, Финляндияне Советлар Союзына каршы юнәлдерергә карар бирү тагын башка планнарга да хезмәт итәргә тиеш булган. Англия һәм Франция Скандинавиядә түбәндәге теләкләрне күздә тотканнар: 1. Нарвикны басып алу юлы белән Германияне төньяк рудасыннан аеру. 2. Скандинавия илләренә Англиянең һәм Франциянең кораллы көчләрен төшереп, төньяк флангдан Германиягә һөҗүм итү өчен яңа фронт төзү. Шуның белән бергә, төньяк илләр Англия—Франция гаскәрләре өчен сугыш мәйданы булып хезмәт итәргә, ә шул ук вакытта төньяк халыклары, Англиянең борынгы традициясе буенча, ярдәмче гаскәрләр ролен уйнарга тиеш булганнар. Рус-фин солых договоры аркасында бу план җимерелгәннән соң Германия хөкүмәте Англиянең һәм Франциянең үзләренең теләкләрен башка формада тормышка ашыру өчен шунда ук маглүм чаралар күргәнлекләрен искә алды. Англия һәм Франция хөкүмәтләре төньякта өзлексез интервенция хәзерләргә маташып, хәзерге сугышта бер нинди нейтралитет булмаска тиеш һәм кечкенә илләрнең бурычы Германиягә каршы көрәштә актив катнашудан гыйбарәт дигән тезисны соңгы атналарда ачыктан-ачык иглан иттеләр. Бу тезис көнбатыш державаларның пропагандасы белән җәелдерелде һәм нейтраль дәүләтләргә политик басымның тагын да көчәйтелүе белән бергә барды. Соңгы вакытларда көнбатыш державаларның Скандинавиягә гаскәр төшерәчәкләре турындагы конкрет хәбәрләр һаман килүләрендә дәвам иттеләр. Көнбатыш державаларның төньякта интервенция ясарга карар бирүләренә моннан элек әле күпме булса да шикләнергә мөмкин булса, соңгы көннәрдә бу шикләр бөтенләй бетте. Германия хөкүмәтенең якын көннәрдә үк инде Англия һәм Франция төньяк дәүләтләрнең территориясен көтмәгәндә басып алырга уйлый дип санарга һич шиксез нигезләре бар. Төньяк дәүләтләр Англиянең һәм Франциянең килеп катышуына каршылык күрсәтмәделәр генә түгел, хәтта үзләренең территориаль суларын бозуга каршы бер нинди чаралар да күрмәделәр. Шунлыктан Германия хөкүмәте әгәр дә Англия һәм Франция үзләренең планнарын тормышка ашыра калсалар Норвегиянең король хөкүмәтенең дә шундый ук позиция алачагын истә тота. Хәтта әгәр дә Норвегиянең король хөкүмәте җавап чаралары күрергә уйласа да, ул чагында да Германия хөкүмәте Англия—Франция хәрәкәтләренә унышлы каршылык күрсәтү өчен Норвегиянең сугыш көчләре җитмәячәкне аңлый. Англия һәм Франция тарафыннан Германия халкына тагылган көрәшнең бу хәл иткеч фазасында Германия хөкүмәте Скандинавия илләренең Германиягә каршы сугыш мәйданына әверелүләренә һәм Норвегия халкының турыдан-турымы, яки читләтепме Германиягә каршы сугышка тартылуына һичбер хәлдә дә түзеп тора алмый. Германия үз дошманнарының планнары тормышка ашуны карап көтеп тора алмый. Германия хөкүмәте бүген Норвегия территориясендә стратегик яктан әһәмиятле пунктларны алу теләге белән маглүм сугыш операцияләренә керешә. Германия хөкүмәте сугыш вакытында Норвегия королевствосын саклауны үз өстенә ала. Моннан соң инде ул төньякта тынычлыкны барлык чаралар белән сакларга һәм аны Англиянең һәм Франциянең һәр төрле казынуларыннан саклауны тәмам тәэмин итәргә карар бирде. Германия хөкүмәте вакыйгаләрнең болай җәелүен теләмәгән иде. Моның өчен Англия һәм Франция җаваплы. Алар икесе дә, ике йөзләнеп, без кечкенә илләрне яклыйбыз диделәр. Чынлыкта исә алар кечкенә илләрне көчлиләр һәм шулай итеп Германияне юк итүгә таба булган һәм торган саен ачык күренеп бара торган омтылышларын тормышка ашырырга өметләнәләр. Германия гаскәрләре Норвегия территориясен дошманлык теләкләре белән алмадылар. Германия армиясенең верховный командованиесе, әгәр дә Англия һәм Франция үзләренең чаралары белән мәҗбүр итмәсәләр, алынган пунктлардан Англиягә каршы көрәшү өчен операция базалары итеп файдаланырга уйламый. Германиянең сугыш операцияләре барыннан да бигрәк Англиянең һәм Франциянең үзләренең терәк пунктларын төзү өчен төньяк илләрнең территориясен басып алуларына комачаулауны теләк итеп куялар. Германия хөкүмәте Германия армиясенең бу чаралары Норвегиянең үзенең интересларына да хезмәт итәрләр дип саный, чөнки алар Скандинавия илләрен хәзерге сугышта үзләренең территорияләре сугыш кырына әйләнүдән саклыйлар. Шуңа күрә дә Германия хөкүмәте Германиянең үзен болай тотуын Норвегиянең король хөкүмәте һәм Норвегия халкы аңлар һәм каршылык күрсәтмәс дип ышана. Һәр төрле каршылык Германиянең кораллы көчләре тарафыннан барлык средстволар белән бастырылачак һәм каршылык күрсәтү һичбер кирәкмәгәнгә кан түгүгә генә китерер иде. Шунлыктан Германия Норвегия хөкүмәтеннән, Германия частьләренең хәрәкәтләренә тоткарлык һәм кыенлык тудырылмасын өчен бик тизлек белән барлык чараларны күрүне үтенә. Һәр вакытта да яхшы булып килгән Германия—Норвегия мөнасәбәтләрен күздә тотып, Германия хөкүмәте, Норвегиянең король хөкүмәтенә, Германиянең хәзердә дә, киләчәктә дә Норвегия королевствосының территориаль бөтенлеген һәм политик бәйсезлеген бозарга уйламавын белдерә“.

Меморандумны пропаганда министре Геббельс радио буенча укыды.

Норвегиянең Германиягә сугыш иглан итүе турында Ассошиэйтед Пресс агентлыгының белдерүе

НЬЮ-ЙОРК, 9 апрель. (ТАСС). Ассошиэйтед Пресс агентлыгының Вашингтоннан хәбәр итүенә караганда, АКШ ның дәүләт департаменты белдерү чыгарган. Белдерүдә болай диелә: „Норвегиянең АКШ тагы илчесе, Норвегиянең Германиягә сугыш иглан иткәнлеге турында дәүләт департаментына хәбәр итте“.

Германия илчесе белән Кутның сөйләшүләре турында Рейтер агентлыгы

ЛОНДОН, 9 апрель. (ТАСС). Рейтер агентлыгының Ослодагы хәбәрчесе Норвегиянең чит ил эшләре министре Кутның Германия илчесе белән сөйләшүләре турындагы белдерүен тапшыра. Кут, Германия илчесенең аңа иртәнге 5 сәгатьтә килгәнлеген һәм Германия гаскәрләренең [illegible] таләпләрне тапшырганлыгын әйткән. Шулай булмаганда,—дигән илче,—Норвегиягә Англия һәм Франция басып алачак. Шуннан соң Норвегия хөкүмәте хәлне тикшерү өчен җыелган һәм Германиянең тәкдименә „Норвегия суверенитетын [illegible]“ Норвегия аларны кабул итә алмый дигән җавап биргән.

ГЕРМАНИЯ АРМИЯСЕНЕҢ ВЕРХОВНЫЙ КОМАНДОВАНИЕСЕ СВОДКАСЫ

БЕРЛИН, 9 апрель. (ТАСС). Германия армиясенең верховный командованиесе хәбәр итә: „Дания һәм Норвегия [illegible] алу операцияләре 9 нчы апрельдә план буенча барды. Даниягә кергәндә бер нинди бәрелешләр булмады. Норвегия ярында Осло янында бер кадәр бәрелеш булып алды. Кич белән Норвегия гаскәрләренең каршылык күрсәтүе бастырылды һәм Германия гаскәрләре Ослога керделәр“.

ДАНИЯ КОРОЛЕНЕҢ ҺӘМ ХӨКҮМӘТЕНЕҢ ХАЛЫККА МӨРӘҖӘГАТЕ

БЕРЛИН, 9 апрель. (ТАСС). Трансоцеан агентлыгының Копенһагендагы хәбәрчесе хәбәр итүенә караганда, Дания короле һәм Дания хөкүмәте тынычлык һәм тәртип саклауга чакырып Дания халкына мөрәҗәгать иткәннәр. Мөрәҗәгатьтә, Дания интересларын саклау теләге белән [illegible]

Норвегиядә Германия гаскәрләренең хәрәкәте

ПАРИЖ, 9 апрель. (ТАСС). Гавас агентлыгының хәбәр итүенә караганда, бүген иртәнге 8 сәгатьтә Осло радиосы түбәндәге хәбәрне тапшырган: „Бүген төнлә белән Норвегия флотының [illegible] Германия гаскәрләре Осло-Фиордка керделәр. Хортен тупка тотылды, [illegible] Берген фортлары каты сугыштан соң Германия гаскәрләре тарафыннан алынды“.

ЛОНДОН, 9 апрель. (ТАСС). Рейтер агентлыгының Парижлагы хәбәрчесе, Ослодан алынган радиохәбәргә караганда, Германия гаскәрләренең Берген, Тронгеймны һәм Эгерсундны (Норвегиянең көньяк ярында) алганлыкларын хәбәр итә.

ПАРИЖ, 9 апрель. (ТАСС). Гавас агентлыгының Стокгольмнан хәбәр итүенә караганда, Норвегиянең Ставангер портын немецләр алганнар.

ЛОНДОН, 9 апрель. (ТАСС). Рейтер агентлыгы Ослодан [illegible] хәбәрне тапшыра: „Германия гаскәрләре Норвегиянең төньяктагы Нарвик портын алганлыклары хәбәр ителә“.

ПАРИЖ, 9 апрель. (ТАСС). Гавас агентлыгы Ослодан алынган түбәндәге хәбәрне тапшыра: [illegible]

[illegible] Тенсберг [illegible] Валлоега 20 [illegible] кеше төшерәләр. [illegible]

НОРВЕГИЯДӘ ЯҢА ХӨКҮМӘТ

БЕРЛИН, 9 апрель. (ТАСС). Германия информация бюросының хәбәр итүенә караганда, анда Норвегиянең яңа хөкүмәте төзелгән. Баш министр итеп Видкун Квислинг билгеләнгән.

ГЕРМАНИЯ АРМИЯСЕНЕҢ ВЕРХОВНЫЙ КОМАНДОВАНИЕСЕ СВОДКАСЫ

БЕРЛИН, 10 апрель. (ТАСС). Германиянең информация бюросы Германия армиясенең верховный командованиесенең түбәндәге сводкасын тапшыра: „9 нчы апрельдә кичкә таба Норвегиянең барлык иң әһәмиятле терәк пунктлары Германия армиясе кулына күчте. Нарвик, Тронгейм, Берген, Ставангер, Кристиансунд һәм Осло шәһәрләре алынды. Норвегия гаскәрләре каты каршылык күрсәткән урыннарда, мәсәлән Ослода һәм Кристиансундта бу каршылык бастырылды.

9 нчы апрельдә кич белән Германия авиациясе Бергеннан көнбатышка таба Англия һәм Франциянең берләшкән хәрби диңгез флотына атака ясады һәм аңа зур югалтулар китерде. Беренче алынган хәбәрләргә караганда, Германия самолетларының һөҗүме нәтиҗәсендә дошманның ике линкоры һәм ике авыр крейсеры бик нык зарарланган“.

ЧЕМБЕРЛЕННЫҢ БЕЛДЕРҮЕ

ЛОНДОН, 9 апрель. (ТАСС). Рейтер агентлыгының хәбәр итүенә караганда, бүген, түбәнге палатада баш министр Чемберлен белдерү белән чыккан.

Башта Чемберлен Норвегия суларында блокаданы көчәйтү буенча һәм аерым алганда анда Германиянең сәүдә пароходлары йөрүне туктату буенча Англия хөкүмәтенең соңгы чараларын искә төшереп үткән. Чемберлен болай дигән: „Союзниклар көчләр чагыштырмасын саклап калу өчен кирәк булачак чараларны күрү хокукын үзләрендә калдырачакларын Норвегиягә белдерделәр. Союзниклар Германия пароходларының хәрәкәтен туктату өчен Норвегиянең территориаль суларында миналар куйдылар“.

Аннары Чемберлен Германия гаскәрләренең Дания һәм Норвегия территориясенә керүләре турында хәбәр иткән. Ул болай дигән: „Бүген тан вактында Германиянең моторлаштырылган һәм пехота частьләре Дания чиген үтеп чыктылар һәм хәзер Дания территориясенең шактый өлеше Германия контроле астында. Хәбәр итүләренә караганда, бүген иртә белән Германия гаскәрләре Копенһагенга килеп кергәннәр. Германиянең Ослодагы илчесенең бүген иртә белән Норвегиянең Германия каршында капитуляция ясавын формаль рәвештә таләп иткәнлеге турында Англия хөкүмәте хәбәрләр алды. Шулай булмаганда, һәр төрле каршылык бастырылачак,—дигән илче. Билгеле, Норвегия хөкүмәте бу таләпне шунда ук кире каккан. Хәзер без инде сугышлар башланганлыкны күрсәтә торган хәбәрләр алдык һәм газеталарның язуына караганда Осло һәм Кристиансунд тупка тотылганнар. Германия гаскәрләре Норвегия ярындагы төрле пунктларга төшкәннәр“.

Аннан соң Чемберлен болай дигән: „Хәрби диңгез көчләре ярдәме белән гаскәрләрне күп кенә портларга бер үк вакытта төшерү белән барган бу операция өчен озак хәзерлек кирәк булган“.

Аннары Чемберлен Норвегиядәге вакыйгалар уңае белән Англия хөкүмәтенең карашын белдергән. Ул болай дигән: Англия хөкүмәте „Англиянең Норвегиягә тулы ярдәм күрсәтергә карар биргәнлеген“ Норвегия хөкүмәтенә бик тизлек белән белдерде. Шуның белән бергә, Чемберлен, хәзерге вакытта Англия флотының куәтле берләшмәләренең диңгезгә чыгып киткәнлеген хәбәр иткән, ләкин диңгездәге операцияләр турында хәбәр бирүдән баш тарткан.

„Англия хөкүмәте Даниягә ярдәм күрсәтергә уйлыймы?“ дигән сорауга Чемберлен: „Мин үзем ясаган декларациягә бер нәрсә дә өсти алмыйм“ дип җавап биргән.

Либерал Мандерның Милләтләр Лигасы Советын чакырырга тәкдим итүенә каршы Чемберлен болай дип җавап бирде: „Һәр эшнең үз вакты бар. Милләтләр Лигасын чакырудан күп нәтиҗәлерәк булган башка чаралар да бар“.

Норвегиянең диңгез министрлегенең белдерүе

ЛОНДОН, 9 апрель. (ТАСС). Рейтер агентлыгының Ослодан алып хәбәр итүенә караганда, Норвегиянең диңгез министрлеге түбәндәге белдерүне иглан иткән: „Германиянең сугыш караблары Норвегиянең яр буе батареяләреннән атылганнан соң төнлә белән Осло-фиордның тышкы өлешендә фортлар яныннан үтеп киттеләр. Иртән 4 сәгат 30 минутта Германиянең сугыш караблары белән Оскарсборг фортлары арасында сугыш булды. Германиянең бер крейсеры фортлар яныннан үткәндә сайга утырды. Башка караблар Хортенны тупка тоттылар. Германия гаскәрләре Тронгеймны алганнар дип уйлыйлар. Берген дә шулай ук оккупацияләнгән. Германиянең бер сугыш карабы Нарвикка килгән һәм Норвегия караблары белән сугышканнан соң кечрәк бер десант төшергән булса кирәк. Шулай ук Германиянең сугыш корабларының Кристиансундтагы фортларга атака ясаганлыкларын хәбәр итәләр. Хәзергә тулы хәбәрләр юк, ләкин Германия самолетларының Кристиансундка һөҗүм иткәнлекләре маглүм. Эдерсундка да Германия гаскәрләре төшерелгән.

ГЕРМАНИЯ ГАСКӘРЛӘРЕНЕҢ ДАНИЯДӘГЕ ХӘРӘКӘТЛӘРЕ ТУРЫНДА РЕЙТЕР АГЕНТЛЫГЫ

ЛОНДОН, 9 апрель. (ТАСС). Рейтер агентлыгының Мальмадагы хәбәрчесе хәзерге вакытта бөтен Даниянең Германия кулында икәнлеген хәбәр итә. Асылда Германия гаскәрләре барлык иң әһәмиятле шәһәрләрне һәм хәрби пунктларны алганнар. Алынган шәһәрләр арасында Копенһаген, Эсбьерг, Корсор һәм Нюберг шәһәрләре бар. Шулай ук немецләр кечкенә Бельтны һәм аның аркылы салынган күперне алганнар. Дания белән Швеция арасында паром хәрәкәте өзелгән. Дания радиостанциясен Германия командованиесе үз кулына алган“.

Осоавиахимның Актаныш район советының Ворошиловча төз атучылары (сулдан) комсомолка С. Хәсәнова һәм З. Корягина иптәшләр ату нәтиҗәләрен карыйлар.

А. Михайлов фотосы (ТатТАСС фотохроникасы).

1 НЧЕ МАЙГА ХӘЗЕРЛЕК

Казанда 1 нче Май бәйрәменә хәзерлек башланды.

Бәйрәмгә хәзерләнү һәм үткәрү өчен хезмәт ияләре депутатларының Казан Шәһәр Советының башкарма комитеты янында, иптәш Мурин председательлегендә, шәһәр комиссиясе төзелде. Предприятиеләрдә, учреждениеләрдә, югары уку йортларында һәм мәктәпләрдә дә комиссияләр төзелә.

ВКП(б) нын Казан Шәһәр Комитеты 1 нче Майга хәзерлек һәм аны үткәрү планын раслады.

СССР Верховный Советының VI нчы Сессиясенең эше турында, 1 нче Май бәйрәме турында, СССР да социализмның җиңүләре һәм Сталинчыл өченче бишьеллыкның бурычлары турында хезмәт ияләре арасында беседалар үткәрелә. 25 нче апрельдән алып, 1 нче майга кадәр клубларда, предприятиеләрдә, учреждениеләрдә, уку йортларында 1 нче Майга багышланган тантаналы җыелышлар үткәреләчәк. Шәһәр мәгариф бүлеге укый-яза белмәүчеләрне һәм аз белемлеләрне укыту буенча массовой чаралар үткәрә. Шәһәрдә балаларның үзешчәнлек сәнгатенә смотр оештырыла.

Шәһәр күләмендәге гомуми демонстрациядә мәктәпләрнең өлкән курсларында укучыларның, осоавиахимчыларның, велосипедчыларның һәм мотоциклчыларның җыелма колонналары оештырылачак. Бәйрәм көннәрендә циркта, театрларда һәм клубларда махсус программалар белән көндез һәм кичен спектакльләр, концертлар бирелә. Бакчаларда һәм мәйданнарда гуляньеләр үткәреләчәк.

Кино-театрларда

Татарстан кинофекация тресты Казанда һәм районнарда 1 нче Май бәйрәмен үткәрү планын төзеде.

Казандагы һәм район үзәкләрендәге кинотеатрлар бәйрәмгә карата бизәләләр, аларда күргәзмәләр оештырылачак. Кино-театрлар Беренче Май бәйрәменә махсус фильмнәр белән тәэмин ителәләр.

Казандагы кино-театрларда 30 нчы апрельдә һәм 2 нче майда балалар һәм кызыл армеецләр өчен өстәмә сеанслар биреләчәк. 1-нче һәм 2 нче майда Ирек мәйданында, шулай ук Кызыл Армия бистәсенең Петров исемендәге мәйданында ачык һавада киносеанслар үткәреләчәк.

Күчмә кинолар бәйрәм көннәрендә районнарда, Беренче Май комиссияләренең күрсәтүләре буенча, алдынгы колхозларда, совхозларда һәм МТС ларда эшләячәкләр. Аларда колхозчыларның үзешчәнлек сәнгате көчләре дә чыгыш ясаячаклар. Күчмә кинолар көндезләрен авыл мәктәпләрендә сеанслар үткәрәчәкләр.

Үзешчәнлек сәнгате көчләренә смотр

Казанның Менжинский исемендәге клубы халыкара пролетариатның бөек бәйрәме—1 нче Майга хәзерлек уңае белән 18 нче апрельдән башлап үзендәге үзешчәнлек сәнгате көчләренә смотр үткәрүгә керешә. Смотр вактында клуб үзенең бер еллык эшенә йомгак ясаячак.

18 нче апрельдә драмколлектив „Тревогалы гудок“ дигән постановкага смотр үткәрә. 23 нче апрельдә исә, яш үсмерләрдән торган коллектив „Мәктәп укытучысы“ дигән пьесаны куя. Клубның җырчылары, биючеләре, декламаторлары һәм музыкантлары да үзләренең аерым номерлары белән катнашалар.

Шулай ук балаларның клуб янындагы музыка мәктәбендә укучыларның да чыгышлары була. Алар бөек рус композиторы П. И. Чайковский музыкаларыннан торган программа белән чыгалар. 30 нчы апрельдә балаларның иҗад көчләренә смотр үткәрелә. Яш авиомодельчеләр үзләренең эшләреннән күргәзмә хәзерлиләр. Хатын-кызларның кисү-тегү түгәрәге тарафыннан да күргәзмә оештырыла.

Смотр барышында иң яхшы табылган номерлар Беренче Майны каршылауга багышланган кичәнең концерт программасына кертеләчәк.

ЕЛГАЛАРДА

Волга суы 10 нчы апрельгә каршы бер тәүлек эчендә Горький янында 31 сантиметр, Югары Ослан янында 42 сантиметр, Тәтеш янында 33 сантиметр, Куйбышев янында 76 сантиметр артты. Югары Ослан янында арткан суның биеклеге 4 метр 50 сантиметр булды. Горький, Вольски һәм Саратов янында боз кузгалды. Куйбышев һәм Сталинград янында боз ага.

Кама суы Молотов янында 24 сантиметр, Сарапул янында 58 сантиметр, Красный Бор янында 40 сантиметр, Чистай янында 30 сантиметр, Лаеш янында 39 сантиметр артты. Молотов, Красный Бор һәм Алабуга янында боз кузгалды.

Бирски янында Агыйдел бозы ага башлады.

Редактор урынбасары И. ҮЗБЕКОВ.
Зам. редактора И. УЗБЕКОВ.

ТАТАРСТАН АССР ДАГЫ БАРЛЫК
АВТОМАШИНА һәм МОТОЦИКЛ ХУҖАЛАРЫ ИГТИБАРЫНА
Татарстан АССР НКВД Эшче-Крестьян Милициясе Идарәсенең
ДӘҮЛӘТ АВТО-ИНСПЕКЦИЯСЕ
1940 нчы ел 20 нче апрельдән авто-мото транспортка
ЯРТЫ ЕЛЛЫК ТЕХНИК ОСМОТР ҮТКӘРӘ
Тиешле инструктаж алу өчен, автомашина һәм мотоцикл хуҗаларына шушы ел 20 нче апрельгә кадәр урындагы милиция бүлекләренә килергә тәкдим ителә.
Дәүләт автоинспекциясе.
593—2—1

25 нче апрель, кич 6 сәгаттә Казан Дәүләт Ветеринария институтының патологик анатомия кафедрасы аудиториясендә, институтның өлкән лаборанты А. К. Малюков тарафыннан халык алдында
ДИССЕРТАЦИЯ
яклау үткәрелә
Тема: „Атларда аяк аралары уретростомиясе“.
Рәсми оппонентлар: ветеринария фәннәре кандидаты доцент В. Г. Зайцев һәм ветеринария фәннәре кандидаты доцент Т. С. Минкин.
Диссертация материаллары белән институтның китепханәсендә танышырга мөмкин.
588—1

ТАТАРСТАН АССР НЫҢ ҮЗӘК МУЗЕЕ
(Чернышевский урамы, 2)
Гражданнар сугышы, хәрби коммунизм, хуҗалыкны аякка бастыру чоры белән бәйләнешле һәм ул чор өчен характерлы булган әйберләр, документлар, фото-рәсемнәр (кораллар, киемнәр, азык документлары, зажигалкалар, гражданнар сугышында катнашучыларның фото-рәсемнәре һәм башка әйберләр)
ҖЫЯ ҺӘМ САТЫП АЛА
455—3—3

ТАТАР ДӘҮЛӘТ ОПЕРА ТЕАТРЫ
Бүген, 11 нче апрельдә Татар Дәүләт Академия театры бинасында
КАЧКЫН
13 нче апрельдә Зур драма театры бинасында
ФАУСТ
Талоннар белән кертелми.
Кич 8 сәгаттә башлана.
Коллектив рәвештә килү өчен 29—04 телефоны буенча заявкалар алына.

ЗУР ДРАМА ТЕАТРЫ
Бүген, 11 нче апрельдә, шулай ук иртәгә, 12 нче апрельдә көндез
КУРКЫНЫЧЛЫ СУД
12 нче апрельдә кич
БАКЧАЛАР ЧӘЧӘК АТА
Талоннар белән кертелми.
Билетлар көндез 11 сәгат 30 минуттан 2 гә һәм кич 5 сәгаттән 7 сәгат 30 минутка кадәр кассада сатыла.

Галиәсгар Камал исемендәге
Татар Дәүләт Академия театры
12 нче апрельдә көндез һәм кич
ШӘМСЕКАМӘР
14 нче апрельдә
КЫЮ КЫЗЛАР
Талоннар белән кертелми.
Спектакль кич 8 сәгаттә башлана.
Касса һәр көн көндез 11 сәгаттән 2 гә һәм кич 5 сәгаттән 9 га кадәр ачык. ТДАТ.

ДӘҮЛӘТ ЦИРКЫ
Бүген һәм һәр көн 3 бүлектә
ЗУР ЦИРК УЕНЫ
ФРАНЦУЗЧА КӨРӘШ
ЯРЫШЫ
ҺӘР КӨН 3 ПАР КӨРӘШӘ
Иртәгә, 12 нче апрельдә
ЗУР ПРОГРАММАДА
КӨНДЕЗГЕ ЦИРК УЕНЫ
Уеннар көндез 12 дә, кич 8 дә башлана.
Касса һәр көн көндез 11 сәгаттән 1 гә һәм кич 5 тән 11 гә кадәр ачык.

БҮГЕН КИНОЛАРДА

„ЭЛЕКТРО“ 10, 12, 2, 4, 6, 8 һәм 10 да.	Тавышлы, художестволы яңа фильм **АРИНКА**
„УНИОН“ 12, 2, 4, 6, 8, һәм 10 да.	**ШАТЛЫК ЭЗЛӘГӘНДӘ**
„КЫЗЫЛ ЙОЛДЫЗ“ 6, 8, 10 да.	**ШӘХСИ ЭШ**
„ЧАТКЫ“ 6, 8, 9-30 да.	**ИСТРЕБИТЕЛЬЛӘР**
„ПИОНЕР“ 11, 1, 2, 4, 6-30, 8 һәм 10 да.	**КАБАРДА АТЛЫСЫ** Көндез 1 сәгаттә мәктәпкә кадәр яштәге балалар өчен сеанс.
„Колхозник“ 6, 8 һәм 10 да.	**ТАШЛАНДЫК**
„РОТ-ФРОНТ“ 6, 8, 10 да.	**КАТЕРИНА**
КУЛЬТУРА САРАЕ 5, 7 һәм 9 да.	**ГРОЗА**

КИРӘК:
АВТОКУЗОВНЫЙ ЗАВОДКА (Эшчеләр бистәсе, Набережный урам, 11) БАШ МЕХАНИК, ФИНАНС БҮЛЕГЕ НАЧАЛЬНИГЫ, КАРТОТЕКАЧЫЛАР һәм 5—6 нчы РАЗРЯД КАЛАЙЧЫЛАР. Хезмәт хакы килешү буенча. Заводның кадрлар бүлегенә килергә. 584—3—3

Ленин исемендәге Сукно фабрикасына (Казан, Киров районы, Гладилов урамы, 59) даими эшкә НОРМАЛАУЧЫ, СЕКРЕТАРЬ-МАШИНИСТКА, ПРОИЗВОДСТВО БУХГАЛТЕРЫ һәм МАТЕРИАЛЬ БҮЛЕК ӨЧЕН КАРТОТЕКАЧЫ. 585—2—2

УПОЛН. ГЛАВЛИТА ТАССР. № А — 1374. ТИПОГРАФИЯ ИМЕНИ АЛЕКСАНДРОВА, ДОМ ПЕЧАТИ 1940 ГОД. ЗАКАЗ № 1373.